АШАУ ТӘРТИБЕ

Мәктәптә балаларны нинди ризык белән сыйлыйлар?

> 15

АЕРЫЛМАГЫЗ!

Россиядә ел саен 600 меңләп гаилә таркала

> 16

СӘРДӘР ТАҺИРОВСКИЙ:

«Күңелдәге театрга хыянәт итәргә ярамый»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 135 (28908) | Җомга | 16 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

vk.com

АМБАР ТУЛЫ, КЕСӘ... БУШ?

ИГЕНЧЕЛӘР АШЛЫК БӘЯСЕНЕҢ АРТУЫНА ӨМЕТЛӘНӘ

Алучыга – сөенеч, игенчегә – көенеч. Быелгы урып-җыю нәтиҗәләрен кыскача гына шулай бәяләргә мөмкин. Уңыш дигәнең шөкер итәрлек булды анысы. Республика кырларыннан рекордлы күләмдә бөртеклеләр җыеп алынды. Урак өсте кызган көннәрдә һава торышы да өметләрне аклады. Җыеп алган уңышның кадере булмау гына күңелгә тия. Ник дигәндә, бүген ашлык бәяләре аның үзкыйммәтеннән дә арзанрак. Алга таба ни булыр? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанда 40 меңгә якын дару әйләнештән алынган. Росздравнадзорның территориаль органы дарулар әйләнешенә дәүләт контроле бүлеге җитәкчесе Гөлназ Сәйфуллина әйтүенчә, дарулар сыйфатына кызәтү ясалган. Шуның нәтиҗәсендә ачыкланган сыйфатсыз дарулар күпләп сатудан алынып, ваклап сату челтәренә китерелмичә калган.
Быел территориаль орган ваклап сатуда барлыгы 495 дару үрнәген тикшергән. Сыйфатсыз дарулар ачыкланмаган. Яз көне Казанда полиция хезмәткәрләре шәһәр офисында дару препаратларын лицензиясез сату очрагын ачыклаган.

Соңгы тәүлектә Татарстанда лаборатория шартларында коронавирусны ачыклау буенча 11984 тикшеренү үткәрелгән. 15 сентябрьгә пандемия башланганнан бирле барлыгы 7331845 тест уздырылган. Роспотребнадзор идарәсеннән хәбәр ителгәнчә, республикада, чир көчәю сәбәпле, тикшерүләр күбрәк уздырыла башлаган. Соңгы 7 көн эчендә үткәрелгән тестлар саны 100 мең кешегә 306,28 курсәткечен тәшкил иткән.
Татарстанда инфекцияне ачыклау буенча тикшеренүләр лабораторияләренең һәммәсе тест-системалар һәм кирәкле материаллар белән тәэмин ителгән.
Сүз уңаеннан, республикада соңгы тәүлектә чир йоктыруның 996 яңа очрагы билгеләнгән.

Татарстанга «Экология» илкүләм проекты кысасында урманнарны торгызу эшләрен башкаруга федераль бюджеттан 3 млн сум күләмендә өстәмә акча бирелгән. Бу акчаны 1100 гектар мәйданда урман культураларын тулыландыру өчен сарыф итәчәкләр. 2022 елда «Экология» илкүләм проекты кысасында «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проектын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан 111,5 млн сум күләмендә акча бүлеп бирелгән иде. Быелгы план буенча урманнарны торгызу эшен 3,6 мең гектар мәйданда башкарырга җыеналар.

Республикада бу атна ахырында һәм киләсе атна башында, көнбатыштан циклон үтеп керү сәбәпле, яңгырлы җылы һава урнашачак. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 17 сентябрьдә республиканың күпчелек өлешендә яңгырлар явып үтәчәк. Көндезге сәгатьләрдә һава температурасының +14...+19 градуска җитүе көтелә. Төнлә +7...+12 градус булыр, дип фаразлана. Якшәмбе – 18 сентябрьдә тагын да җылырак: көндез термометрның терекөмеш баганасы +17...+22 градус күрсәткечен күтәрәчәк. Төнлә дә җылы: +9...+14.
Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, дүшәмбе – 19 сентябрьдә Татарстанда җәй җылысы хөкем сөрәчәк. Кыска вакытлы, урыны белән яшенле яңгырлар булачак. Көндез һава температурасы +20...+..26 градуска җитәчәк, төнлә +11...+16 градус булачак. Сишәмбе – 20 сентябрь көнне исә республикага салкын һава агымы кыска вакытлы яңгырлар алып киләчәк. Көндез һава температурасы берникадәр төшә: +18...+23 градус җылы көтелә.

ГАЗ КУӘТЕ

tatarstan.ru

Татарстанда водород ягулыгында эшли торган заманча судно төзеләчәк. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Санкт-Петербургка эш сәфәре кысасында шул хакта килешү имзаланды.

Президент анда XI Петербург халыкара газ форумында катнашу өчен барды. Рөстәм Миңнеханов видеоэлемтә аша Татарстанда өч яңа объектны эшләтеп җибәрүдә дә катнашты.

Рөстәм Миңнехановның элек Экспофорум мәйданчыгында оештырылган күргәзмәдә булды. «Газпром» ГАҖ идарәсе рәисе урынбасары Виталий Маркелов белән бергә ул республика оешмалары һәм югары уку йортлары тарафыннан әзерләнгән экспозиция белән танышты. «КАМАЗ» павильонында «Газпром» оешмасы заказы буенча эшләнгән КамАЗ-6250 вахта автобусын тәкъдим иттеләр. 32 кеше йөртү генә түгел, яңа кузовта күчмә лаборатория, сөйләшү офисы, медицина кабинетлары, инженерлык үзәге, идарә итү пункты урнаштырырга мөмкин. «Газпром» павильонында исә Рөстәм Миңнеханов диңгез өстенән пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен билгеләнгән, үзебездә төзелгән беренче Ми-171А3 вертолетын карады. Проектта, Казан вертолетлар заводын да кертеп, берничә предприятие катнаша.

Президент Горький исемендәге Яшел Үзән заводы белән Крыловский дәүләт фәнни үзәге арасында килешү имзалау тантанасында да катнашты. Татарстанда водород ягулыгында эшли торган заманча судно төзергә җыеналар. Бу эштә Россиядә әлегә кулланылмаган технологияләрдән файдаланмакчылар.

Петербург халыкара газ форумы кысасында Рөстәм Миңнеханов «Газпром» ГАҖ идарәсе рәисе урынбасары Олег Аксютин белән очрашты. Очрашуда республиканың газ инфраструктурасын үстерү, газ-мотор ягулыгы базарын киңәйтү, шулай ук уртак проектларны гамәлгә ашыруның барышына бәйле мәсьәләләр турында фикер алыштылар.

Санкт-Петербургка эшлекле сәфәр кылган Рөстәм Миңнеханов видеоэлемтә аша Татарстанда өч яңа газмотор инфраструктурасы объектын эшләтеп җибәрүдә дә катнашты. Шуларның беренчесе Биектау районында ачылды. Биредә «Садилово» сыекландырылган табигый газ җитештерү, саклау һәм төяү комплексын эшләтеп җибәрделәр. Ул сәгатенә – 1,5 тонна, елга 13 мең тонна чамасы сыекландырылган газ җитештерергә сәләтле. Ул "Газпром сыекландырылган газ технологияләре» (КриоТЗП) оешмасының Татарстанда, Ленинград өлкәсе һәм Санкт-Петербургта урнашкан ягулык салу станцияләренә җибәреләчәк.

– Завод барлыкка килгәч, аннан файдаланучылар да булачак. Без кысылган һәм сыекландырылган газ табу буенча актив эшлибез. Киләчәккә планнарыбыз зур. Безнең проектларга ярдәм итүләре өчен «Газпром» җитәкчелегенә рәхмәт белдерәсем килә. Экономияләү һәм уңай экологик нәтиҗә – газ-мотор ягулыгының өстенлекләре булып тора. Сыекландырылган табигый газга күчү безнең шәһәрләрнең экологиясен шактый яхшыртачак, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Бу көнне Теләче районында да табигый газны сыекландыру буенча тагын бер комплекс ачылды. Беренче этапның егәрлеге сәгатенә 1,5 тонна тәшкил итә. Киләчәктә аны сәгатенә 6 тоннага җиткерергә җыеналар. Президент катнашында видеоэлемтә аша ачылган объектларның өченчесе Чаллыда сафка басты. Биредә кысылган газ һәм водородта эшләүче ягулык салу станциясе эшли башлады.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында Фәләстыйн делегациясе белән очрашты. Чит ил кунаклары Казанга Россиягә сәфәрләре кысасында килде.

Очрашуда Рөстәм Миңнеханов 2014 елдан бирле җитәкләгән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме кысасында багланышлар мәсьәләләре буенча фикер алыштылар. «Төркем кысасында бездә зур эш алып барыла. Безнең Фәләстыйндагы коллегаларыбыз да актив катнаша», – диде Татарстан Президенты. Ул республиканың Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасына (ИХО) керүче илләр белән хезмәттәшлек иткәнен дә әйтте. Быел Татарстанда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы билгеләп үтелде. Шулай ук ел саен ИХО ярдәме белән Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисади саммиты уза.

Казанда шәһәр метросының икенче линиясендә чираттагы тоннельне казый башладылар. «Айсылу» тоннель казу комплексы Ломжа урамыннан 10 нчы микрорайон ягына таба кузгалды. Эш барышын Президент Рөстәм Миңнеханов барып күрде.

«Казметрострой» АҖ генераль директоры Марат Рәхимов әйтүенчә, «Сахаров урамы» станциясеннән (яңа исеме – «Тулпар») «Ломжа урамы» (яңа исеме – «Зилант») станциясенә кадәр участокны казу инде тәмамланган. Тоннельнең гомуми озынлыгы 2,2 км тәшкил итә. Марат Рәхимов сүзләренчә, Казан метрополитенының киләчәгенә килгәндә, берничә проектны исәптә тоталар: «Универсиада Авылы»н да кертеп, Республика клиник хастаханәсенә (РКБ) кадәр ике станция ясау, йә төп игътибарны икенче линиянең Компрессорлар заводына кадәр дәвам итәчәк икенче участогына бирү.

Казан метросының икенче тармагының беренче өлешен төзүне 2027 елда тәмамларга җыеналар. Ул дүрт – «Зилант», «Тулпар», «ТАССРның 100 еллыгы» һәм «Академия» станцияләреннән тора. Гомумән алганда, икенче линиядә дүртәр станцияле барлыгы өч блок булыр дип көтелә.

Бер казанда кайныйсы

21–24 сентябрьдә Татарстан башкаласында Kazan Digital Week халыкара форумы узачак. Өченче мәртәбә оештырылучы чарада IT тармак белгечләре, сәясәтчеләр, төбәк башлыклары, бизнес вәкилләре, галимнәр катнаша. Бу юлы алар хәзерге шартларда социаль-икътисади, фәнни-техник үсеш юлларын табу турында сөйләшәчәк.

Kazan Digital Week форумы – «акыллы» транспорт системалары, интернеттагы куркынычсызлык, тормышның һәр тармагына тамыр җәйгән цифрлы технологияләр турында сөйләшү, фәнни алгарыш, яңалыклар, тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгы да әле ул. Быел күргәзмә, ярышлар урыны да. «Казан Экспо» үзәгендә узачак чара быел мәйданы ягыннан да зуррак булыр дип көтелә. Ә кемнәрне кунакка дәшкәннәр?

– 10 төрле юнәлеш буенча 120ләп тематик чара узачак. Бу – «түгәрәк өстәл»ләр, фикер алышулар, секцияләр. Хәзерге вакытта 865 кеше чыгыш ясарга теләк белдерде. Зур форум кысасында алар үз юнәлешләре буенча чыгыш ясаячак, – дип сөйләде Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин. – Быел күргәзмә мәйданын ике тапкыр арттырдык. Россиядәге IT компанияләр форумга кызыксыну белән карый. Илнең барлык төбәкләреннән киләчәкләр. 10 мең квадрат метр мәйданда 140лап экспонат урнашачак.

– Форумның көн тәртибендә Россия IT индустриясе, сәнәгать, бизнес, фән алдында торган бурычлар һәм базарга тәкъдим итәрлек мөмкинлекләр хакында сөйләшү булачак. IT базары чит илләр белән генә чикләнми әле ул, – диде Айрат Хәйруллин.

Халыкара форум булгач, катнашучылар географиясе дә Россия белән генә чикләнми, билгеле.

– Форумда катнашырга 32 дәүләт вәкиле теләк белдерде. Болар – Абхазия, Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан, Молдова, Үзбәкстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Мисыр, Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Иран, Төркия, Бельгия, Бөекбритания, Венгрия, Испания, Швейцария, Андорра, Кытай, Һиндстан, Индонезия, Алжир, Ангола, Кения, Нигерия, Кот-д`Ивуар. Моннан тыш АКШ вәкиле дә киләчәк, – диде Айрат Хәйруллин.

Чараның пленар утырышы 23 сентябрьдә узачак. Федераль дәрәҗәдәге кунакларның да сәламләү сүзе белән чыгыш ясавы көтелә. Гадәттәгечә, форумда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашачак. Моннан тыш, тәүге тапкыр «Дәүләт – элемтәдә» дигән федераль конференция узачак.

– Бу конференциядә Россия цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры Мәкъсүт Шадаев һәм VK компаниясе җитәкчесе Владимир Кириенко катнашачак. Моннан кала илнең барлык 85 төбәгеннән цифрлаштыру тармагы өчен җаваплы кешеләр, безнең коллегалар катнашуы каралган, – диде Айрат Хәйруллин. – Дәүләт хезмәтләре белән халык арасындагы элемтә турында фикер алышачакбыз. Әйтик, социаль челтәр аша ничек итеп табибка язылырга? Һәм башка шундый сораулар күтәреләчәк.

Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе советы рәисе Рифкать Миңнеханов әйтүенчә, бу форум хәзерге вазгыятьтә аеруча актуаль. Читнекенә алмашны үзебездән эзлисе, «акыллы башлар»ның үзебездә булганнарына ышанасы бит.

tatarstan.ru

– Цифрлаштыру елы бара. Форум кысасындагы күргәзмә һәрвакыт фәнни-техник үсеш өчен бер этәргеч булып торды. Монда килеп, фәнни алгарыш саналган нәрсәләр белән танышырга, тотып, үз күзләрең белән күрергә мөмкинлек бирелә. 200дән артык компания үз стендларын тәкъдим итәчәк. Форумның партнерларына да рәхмәтебез зур.

Форумның тагын бер яңалыгы: күргәзмә кысасында югары уку йортлары белән киберкуркынычсызлык буенча белгечләр әзерләү турында килешү имзаланачак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КӨЗГЕ ЧАКЫРЫЛЫШ

ДЕПУТАТЛАР ЯЛДАН СОҢ БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШКА ҖЫЕЛА

Дәүләт Советы депутатлары көзге сессиянең тәүге утырышына 23 сентябрьдә җыелачак. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул иттеләр. Депутатлар 28 мәсьәлә, шул исәптән 19 республика законы проектын, 2 федераль закон проектын һәм Россия субъектлары закон чыгару органнарының 2 мөрәҗәгатен карап тикшерергә ниятли.

«Парламент каникулы тәмамланды, законнар иҗат итү буенча актив эш башлана, – диде Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Киләсе утырышның көн тәртибенә чыгарылган мәсьәләләр республикабызда яшәүчеләрнең барчасын борчый».

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, 5 закон проекты республика Бюджет кодексына һәм салым законына үзгәрешләр кертүгә бәйле. Кайбер закон проектлары – ташламалы салым ставкаларының гамәлдә булуын озайтуны, кайберләре республика законын федераль законга туры китерүне күздә тота.

Социаль сәясәт комитеты тәкъдиме белән, үсмерләргә хәмерсез эчемлекләр һәм составында углеводород газы булган товарлар сатуны чикләү турында закон проекты беренче укылышта каралачак. Лилия Маврина әйтүенчә, бу мәсьәлә Дәүләт Советына үтмәгән сәяси партияләр вәкилләре катнашында тикшереләчәк. Федераль закон нигезендә, һәр ел саен шундый эш ысулы кулланыла.

Моннан тыш инвестицион эшчәнлек һәм шәһәр төзелеше эшчәнлегенә турында, җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге кайбер мәсьәләләрне җайга салу, янгын куркынычсызлыгы турында һ.б. республика законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан закон проектлары беренче укылышта карап тикшереләчәк. Ә инде Татарстан Сайлау кодексына һәм сайлаулар, референдумнар үткәргәндә ерактан торып электрон тавыш бирү мөмкинлеген билгеләүче кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында закон проекты икенче укылышка чыгарылган.

Киләсе утырышның көн тәртибенә кайбер муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, Казан шәһәре һәм Биектау районы чикләренә кагылышлы республика законнарына үзгәрешләр кертү («Фәнни шәһәрчек»не Казан территориясенә кертү ягыннан), Татарстан белән Мари Иле Республикалары арасындагы чикнең урнашу тәртибен билгеләү турында килешүне раслау хакында закон проектлары кертелгән.

Утыз дүртенче утырышта депутатлар мәгариф һәм фән министрының чыгышын да тыңлаячак. «Хөкүмәт сәгате» кысасында Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева Татарстанда балаларны яклау һәм саклау өчен башкарылган эшләр турында сөйләячәк.

Парламентчылар шулай ук ау кагыйдәләрен бозган өчен минималь штраф күләмен 500 сумнан 2000 сумга җиткерүне күздә тоткан федераль закон проектын Дәүләт Думасына кертү турында Дәүләт Советының закон инициативасын караячак.

Моннан тыш утырышның көн тәртибенә, вәкаләтләре вакыты чыгу сәбәпле, Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү мәсьәләсе кертелгән. Моңа бәйле рәвештә вакантлы җиде урынга 11 гариза тапшырылган.

ЧҮПРӘЛЕДӘ – ДУСЛЫК КҮПЕРЕ

Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Чувашия Дәүләт Советының Социаль сәясәт һәм милли мәсьәләләр комитетының уртак күчмә утырышы Чүпрәле районында узды. Мөнәсәбәтләрне ныгыту өчен алга таба нинди эшләр башкарылачак? Утырышта әнә шулар турында сөйләштеләр.

Утырыш башланыр алдыннан ике республика депутатлары Яңа Убi һәм Иске Чүпрәле авыллары мәдәният йортлары эшчәнлеге белән танышты. Кунакларны фольклор коллективлары җыр-бию, татар һәм чуаш халыкларының милли ризыклары белән каршы алды. Сәнгать осталары чуаш халык костюмнары, традицион бизәнү әйберләре күргәзмәсен тәкъдим итте.

Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов әйтүенчә, мәдәни традицияләрне, халык иҗатын, мәдәни күптөрлелекне саклау мәсьәләсе безнең күпмилләтле илебез өчен һәрвакыт актуаль.

– Заманча технологияләрдән башка сәнгатьне һәм мәдәни мирасны популярлаштыру мөмкин түгел. Бүгенге уртак эш әлеге тема буенча тупланган тәҗрибә белән уртаклашырга һәм алдагы эш юнәлешләрен билгеләргә мөмкинлек бирер дип өметләнәбез, – диде ул утырышны ачканда.

Депутатлар ике республиканың парламент җитәкчеләре Фәрит Мөхәммәтшин һәм Леонид Черкесов рәислегендә мәдәни традицияләрне саклауда заманча технологияләр кертү буенча фикер алышты. Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, Чүпрәле районы очраклы гына сайланмаган.

– Чүпрәлене Чувашиягә якын булганга түгел, монда бик күп чуаш милләте вәкилләре дус-тату яшәгәнгә сайладык. Алар үз телен, традицияләрен, мәдәниятен, киемен саклап калган. Без моңа Чүпрәледә тагын бер кат инандык. Халыкларыбызның күпмилләтле, күптелле, күпмәдәниятле булуы – безнең өчен иң зур кыйммәт, – диде Татарстан парламенты Рәисе. – Тәҗрибә уртаклашу һәрчак ниндидер яңалык алып килә, безне берләштерә. 173 милләт вәкиле тату гаилә булып, һәркем үз ихтыяҗын сизеп яшәсен өчен нишләргә? Республикада моңа бик җентекле, зур эш белән ирешәбез.

Фәрит Мөхәммәтшин чуаш халкын Татарстанның мәдәни һәм рухи тормышы үсешенә, икътисадына зур өлеш кертә торган хезмәт сөючән халык дип атады.

– Без сезне күрүебезгә бик шат. Татарстанга килеп, монда милләтара тынычлык һәм татулык өчен күп эшләр башкарылуына тагын бер кат инаныгыз. Күпмилләтлелек, тату тормыш, мәдәни кыйммәтләр – болар безнең өчен бик мөһим, – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Леонид Черкесов республика үсешендә Татарстанның зур роль уйнавын әйтте.

– Чувашия белән Татарстан арасындагы чик безне аермый, ә якынайта. Чуашлар һәм татарлар арасын күпгасырлык дуслык, бер-беребез белән аралашу һәм ярдәм итешү берләштерә. Чувашиядә татарлар халык саны буенча өченче урында тора. Бездә 30 меңнән артык татар яши. Татарстанда да чуашлар сан буенча өченче урында тора. Биредә 120 мең чуаш яши. Татарстан җитәкчелегенә республикада чуаш телен һәм мәдәниятен үстерүгә зур игътибар биргәне өчен зур рәхмәт! Республикада чуаш этномәдәни компоненты булган мәктәпләр һәм балалар бакчалары эшли, чуаш телендә «Сувар» республика газетасы, район газеталары нәшер ителә. Бу үзара хөрмәт һәм дуслык турында сөйли, – диде Леонид Черкесов.

Чувашиянең Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, бүген яшьләр өчен ата-бабаларыбыздан калган мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау аеруча мөһим. «Ике комитетның уртак утырышы үз нәтиҗәләрен күрсәтер дип ышанабыз», – диде Черкесов.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов цифрлаштыруның мәдәният өчен дә мөһим булуын әйтте. Аның сүзләренчә, республика мәдәният йортларында, китапханә һәм музейларда мәдәни чараларны трансляцияләү өчен 10 виртуаль концерт залы эшли. Татарстан Милли электрон китапханәсенең цифрлаштырылган басмалары фонды мең китап белән тулыланган.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла чуаш һәм татар телендә шигърият антологиясе чыгарырга тәкъдим итте.

– Якутлар белән поэзия, проза антологиясен ясадык. Алар – татар шигърияте, без якут шигъриятен һәм прозасын бастырдык. Шигырь – халыкның җаны. Сезнең белән дә бу юнәлештә эшли башларбыз дип өметләнәм. Милләтара мөнәсәбәтләр, халыклар дуслыгы, дибез. Бу буш сүзләр килеп чыга бит. Гамәлдә күрсәтергә кирәк, – ди язучы.

Утырыш фикерләр әйтү, тәкъдимнәр җиткерү белән генә чикләнмәде. Якын арада ике республика парламенты җитәкчеләре элемтәләрне ныгыту турында килешү имзалаячак.

Ләйсән САФИНА

Әйтеп кенә бактым

Калька

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Тел турында сөйләшеп утырганда, бер дустым: «Тәмле итеп сөйләгән кешене тәмле әйбер ашаган кебек рәхәтләнеп тыңлап утырасың», – дигәнрәк сүзләр әйткән иде. Мин исә: «Тәмсез сөйләгән кешене тыңлаганда күңел болгана», – дип өстәгән идем. Инде менә ничә еллар узгач, әлеге сөйләшү яңадан искә төште. Төшмәс иде, сәбәбе бар: телебез тәмсезләнә бара.

Мин моны татар теленең «бәйсезлеге» югала бару белән дә бәйлим. Һәр телнең интернациональ сүзләргә баюы табигый инде ул, тик алар безне артык басып китә башлады кебек. Гомер буе «күрше тавыгы»на кызыгып яшәгән Россиядә башкача булмый да, ахрысы. Сөйләшкәндә бер генә чит сүз кыстырсак та, без үзебезне бер башка үсеп киткәндәй итеп тоябыз. Круто, да?

Телнең тәмсезләнүендә, чүпләнүендә аны кулланган кеше үзе гаепле. «Син болай әйт, болай итеп сөйлә!» – дип, берәү дә авызга китереп сукмый. Дөрес, телне зәгыйфьләндерү, аны кулланылыштан кысрыклап чыгару өчен дәүләт күләмендә дә күпмедер дәрәҗәдә эш башкарыла. Мондый сәясәткә каршы тормаган, дөресрәге, торырга теләмәгән өчен кемне гаеплисең?

Хәтерлим, Татарстанның бәйсезлеге турында Декларация кабул ителгәч, ана телебез дәүләт теле статусы алгач, кайбер депутатларыбыз, законнарны да ике телдә кабул итәргә кирәк, дигәннәр иде. Ягъни закон язылганда ук ике телдә язылырга тиеш. Тик бу тәкъдим колак яныннан выжлап узды да китте. Җаваплы иптәшләр, бәлки, Мәскәүдән шүрләгәннәрдер, бәлки, урыс кардәш «обидется» дип уйлаганнардыр, ә, бәлки, үзләренә өстәмә мәшәкать аласылары килмәгәндер. Бит закон татар телендә язылса, кабул ителсә һәм гамәлгә керсә, бездә татар теле урыс теле белән бер дәрәҗәдә кулланылырга, хакимият әһелләре татарчаны су кебек эчмәсәләр дә, ипилек-тозлык белергә, һәрхәлдә, икенче дәүләт теленә дә хөрмәт белән карарга тиеш була. Без үз эшендә ике дәүләт телен дә кулланганнарга өстәмә түләүгә кагылышлы закон проектын да хупламадык. Чөнки кемнәрдер, йомшак кына әйткәндә, «обидеться могут» дип уйлаганбыздыр.

Ниһаять, ана телебез «калькалар чоры»на килеп керде. «Калька» – француз сүзе, «чит тел элементын алып эшләнгән берәмлек» дигәнрәк мәгънәдә. Ягъни «күчермә», «копия» була инде. Аның «копия»се дә латинча бит әле, безнеңчә «күплек» дигән мәгънәне аңлата. Бүген телебез шактый ук дәрәҗәдә «калька», «копия» чолганышында яши. Сүзнең, җөмләләрнең матурлыгы, тәме генә түгел, мәгънәләре дә үзгәргәли. Бездә хәзер бөтен эш кәгазьләре дә диярлек рус телендә. Татарчалары, нигездә, әлеге дә баягы «калька».

Һәр телнең җөмлә төзелеше – үзенчә, сүзгә-сүз тәрҗемә беркайчан да тулы, дөрес мәгънә биреп бетерә алмый. Яшь вакытта концертларда сөйләп йөргән бер мәзәгем искә төште әле. Ул нәкъ менә татарчадан урысчага тәрҗемә турында иде. Бер ата белән ана шәһәрдә яшәүче улларына хат язалар. Ә уллары инде татарчасын онытып та өлгергән була, әти-әнисенә «пишите по-русски» дип хат яза. Нишләсеннәр, әти белән әни өйләренә урысча белгән кешене дәшеп, хатны урысчага тәрҗемә иттерәләр. Хат «письма голова, пиши против», ягъни «хат башы, яз каршы» дип башлана. Авыл яңалыклары язганда болар «шайтан суы аркасында персидәтел Шәрифне эшеннән чыгарып аттылар» дияргә дә онытмыйлар. Урысчага тәрҗемәсе болай: «На спине чертовой воды председателя Шарифа вынесли с работы и застрелили». Хат укыганда тамашачы тәгәри-тәгәри дигәндәй көлә иде.

Әмма көлке астында «көллесе» дә була бит аның. Концерт тәмамлангач, яныма килеп: «Телебезне кадерсезгә чыгарып бетерәбез инде, име, энем!» – дип тә әйткәлиләр иде. Ни кызганыч, тел кадерсезләнүгә бүген телевидение, радио, басма матбугат та үз өлешен кертә. Мисаллар китереп язып тормыйм инде, бүгенгә, диюем. Дальше «глаз увидит».

Безнең телебез гаҗәп бай, бу байлыкны күреп-белеп кенә бетермибез әле. Шуңа күрә ул төссезләнә, тәмсезләнә, кадерсезләнә бара кебек. Как жаль!

ДӨНЬЯКҮЛӘМ ТҮНТӘРЕЛЕШНЕ КӨТКӘНДӘ,

ЯКИ ТИЛЕЛӘР ЙОРТЫН ИНВЕСТИЦИЯЛӘҮ

pixabay.com

Дөнья икътисадында аек акылга сыймый торган вакыйгалар чылбыры дәвам итә. Сишәмбе көнне Америка финанс базарларында тагын бер мәтәлчек булды: спекулянтлар 5 процентка якын акчасын югалтты.

Глобаль капитализмның андый түнтәрелешләре гаҗәпләндерми безне, чөнки аның табигате шундый. Фонд базарындагы уеннарга катнашасың икән, бүген отасың, иртәгә оттырасың. Әмма дә ләкин бүген мәйданга чыгып килүче кризис моңарчы кешелек тарихында күзәтелгән барлык кризислардан да принципиаль рәвештә аерыла. Дәүләт җитәкчеләре, бизнес-лидерлар аек акылга сыймый торган адымнарны шулкадәр күп ясый: безнең барыбызны да кемнеңдер куәтле кулы фаҗигагә таба махсус этәрә, дигән вәсвәсә килә күңелгә. Иртәгесе көнгә ышаныч шул дәрәҗәдә югала: байлыгы барлар мал саклау өчен яраклы бер генә чара да таба алмый. 2008 елгы кризисны алдан әйткән трейдер Майкл Бьюрри үзенең барлык акцияләрен дә, кыйммәтле кәгазьләрен дә сатып бетерде дигән хәбәр алынганга да айга якын вакыт үтте инде. Ул бары тик Geo Group акцияләрен генә сатмаган. Ә Geo Group хосусый төрмәләр һәм тиләләр йортларын инвестицияли. Бу ике йортка Көнбатыш дөньясында, чынлап та, зур ихтыяҗ бар һәм артачак. Фетнә потенциалы үсү сәбәпле, котылгысыз рәвештә репрессияләр көчәячәк, димәк, төрмә тотучыларга заказлар арту табигый.

Бостон университетының Җәмгыять сәламәтлеге мәктәбе галимнәре шулай ук бер ай тирәсе элек кенә үз тикшеренүләрен игълан итте. Аның нәтиҗәләреннән аңлашылганча, Америка студентларының 60 проценттан артыгы кимендә бер психик тайпылыштан интегә. 2013 ел белән чагыштырганда бу күрсәткеч 50 процентка арткан. Шулай булгач, трейдер Бьюрриның акчасын тилеләр йорты акцияләренә тыгуында зур рациональ орлык бар.

Әйдәгез, гадәти намуслы кешенең үз-үзен тотышындагы табигыйлек күрсәткечләренә игътибар итик. Ул үзе турында начар уйлауларын теләми, шуңа күрә үзенә тапшырылган бурычны җиренә җиткереп башкарырга омтыла. Нормаль җәмгыятьтә халтурщикларның, эшкә бармак аша караучыларның бер дә бәясе юк бит инде. Адәм баласына исә абруен саклау теләге, маркасын югары тоту омтылышы хас. Берәү дә үзе турында чүп кеше, пүчтәк дип уйлауларын теләми. Киресенчә, аерым кыйммәтләргә ия шәхес буларак бәяләнүне ярата. Коллективта шундыйлар өстенлек ала икән, ул коллективка теләсә нинди бурычны башкарып чыгу кыенлык тудырмый. Милләт тә күпчелек җаваплы кешеләрдән торса, халык алгарыш кичерә, үзен пассионар милләт итеп таныта. Европада иң куәтле дәүләт кайсы әле? Әйе, Германия. Ике Бөтендөнья сугышында да котчыккыч җиңелүгә дучар булуга карамастан, немецлар бик тиз аякка басалар һәм икътисад дилбегәсен үз кулларында тота башлыйлар.

Аларның шул рәвешле лидерлыкка чыгуларының сәбәбе табигый байлыклар өстендә утыруда түгел, бөтенләй башка нәрсәдә. Серне ачу өчен бер факт китерик. Бөек Ватан сугышыннан соң Азәрбайҗанда – совет республикаларының берсенең башкаласы Бакуда Хөкүмәт йорты төзи башлыйлар. Бинаны әсирлеккә төшкән немецлар төзи. Немец төзесә, яхшы итеп төзи инде ул, моны һәркем белә. Ләкин көннәрдән бер көнне әсирләр бердәм рәвештә эштән баш тарталар, забастовка игълан итәләр. Сәяси җәнҗал исе чыга. Бу хакта ишетеп, Азәрбайҗан Компартиясе Үзәк Комитетының беренче секретаре Мирҗафар Багиров төзелеш мәйданына үзе килә. Немецлар исә ачлыктан да, хезмәткә түләүнең начар булуыннан да зарланмыйлар. «Начар сыйфатлы цемент китерделәр, шуңа эшне дәвам итә алмыйбыз», – диләр. Җитәкчелек аптырашка кала. «Сез – әсирләр, сезнең ни эшегез бар, төзелешне дәвам итегез», – дип гаҗәпләнә. «Без моны немец халкы исеменнән төзибез, – ди әсирләр. – Шуңа күрә монда кимчелекләр булырга тиеш түгел». Үз милләтенең абруен кайгырткан әсирләр алдында җитәкчелек чигенергә мәҗбүр була. Яхшы сыйфатлы цемент китертәләр. Германиядәге немец икътисади могҗизасының төп серен аңлагансыздыр дип уйлыйм.

Инде хәзерге немец икътисадына килик. Миллионлаган тираж белән чыгучы Spiegel журналы: «Немец икътисадын «биш акттан торган трагедия» һәм рецессия көтә», – дип яза. Концерн җитәкчеләре һәм профсоюз лидерлары икътисади коллапс һәм зур тизлек белән үсүче эшсезлек алдында котлары алынып куркуларын яшереп тормыйлар. Economist журналы: «Германия энергокризис нәтиҗәсендә бөтен сәнәгать системасын югалтырга мөмкин», – дип кисәтә. Немецларга ни булган? Зур сугыш кичерделәрме? Юк. Табигый стихия аларның илен җимереп ташладымы? Юк. Алар сәясәтчеләренең илне ясалма рәвештә энергетик кризиска тартып кертүләренә каршы тора алмый.

Евросоюзда гаҗәп кагыйдәләр кертелде соңгы елларда. Германия, әйтик, бик бай табигый газ ятмалары өстендә утыра. Чыгарырга ярамый. Польшада сыйфатлы ташкүмергә бай булган шахталарга йозак элингән, чөнки Евросоюз кагыйдәләре ташкүмер чыгарырга рөхсәт итми. Читтән сатып алырга рөхсәт, үзеңнекен чыгарырга – юк. Энергия чыганакларына бәяләр котырып үсә башлаган мизгелдә немецлар һәм французлар үзләренең атом-төш станцияләрен туктатып бетерделәр диярлек. Хәзер французлар ашыгыч рәвештә яңадан кабызып азапланалар, немецлар эштән чыгып бетмәгән ике станциянe кузгалтып булмас микән дип уйлана. Италия – газ чыгаручы Европа илләренең берсе – үзенең газ скважиналарын бикләгән. Шуларга өстәп европалыларның Россия белән ызгышып, Себер табигый газыннан колак кагарга башлары җитте. Хәзер Европаның барлык корыч кою заводлары эштән туктап киләләр. Аек акылдан баш тарту бик кыйбатка төшә көнбатышлыларга. Ә бит барысы да ирләр юк, хатын-кызлар юк, дип юләрләнүдән башланды. Бер җөнесле гаиләләр төзүне максат итеп куйган глобаль идеология миләрне шулкадәр какшатты: халыкларның уңай милли сыйфатлары юылды, рациональ акыл юкка чыкты.

Кайтандыр кешеләр тигез дип расларга омтылган, сәләте һәм байлыгы белән башкалардан аерылып торучыларны эзәрлекләгән һәм лагерьларга озаткан коммунистик идеология СССР киңлекләрендә яшәүче халыклар белән шулай усал шаярткан иде. «Тисә тиенгә, тимәсә ботакка» дигән принцип белән яшәү һәм эшләү гадәткә керде. «Үзем тапкан мал түгел, әтинеке җәл түгел» дигән кагыйдә дә үзен озак көттермәде. «Уртак малны эт ашамас» дигән әйтем үз куәтен бөтен көченә раслады: дәүләт малын исраф итүне чүпкә дә санамадык. Нәтиҗәдә гигант заводлар төзеп куйдык та аларны туксанынчы елларда металлоломга озаттык.

Көнбатыш моңарчы күрелмәгән санкцияләр кертә башлагач, барысы да искә төште. Үзебезнең авиация заводлары бар иде, бик үк яхшы сыйфатлы булмаса да, пассажир очкычларын күпләп үзебез җитештерә идек. Хәзер шул заводларны яңадан эшләтеп җибәрергә кирәк, әмма койрык бозга каткан. Менә үзбәкләр хәбәр итә. Россиянең сәүдә вәкиле Константин Злыгостев Ил-76, Ил-114 самолетларына запчастьлар җитештерүче Ташкент механика заводына килгән. Заводның генераль директоры Зафар Исоков белән уртак Россия – Үзбәкстан проектларын тикшергәннәр. Завод үткән ел нибары 9 миллион долларлык кына запчасть җитештерә алган. Бу – авиация өчен чүп күрсәткеч. Үзбәкләр ачы үкенеп белдерә: илнең авиация тармагындагы потенциалы торгызa алмаслык булып юкка чыгарылган. Уникаль җиһазлар металлолом бәясеннән Иранга озатылган, белгечләр базарда бәрәңге сата... Бөтен СССР буенча шул хәл булды бит инде. Зуррак авылларга керсәң дә, кайчандыр гөрләп эшләп торган завод хәрабәләренә юлыгасың. Сөт заводларына кадәр чүплеккә ташланды. Хәзер менә дөньякүләм зур түнтәрелеш барганда, бик кирәк алар безгә. Әмма терсәк якын да, тешләп булмый шул. Акчаны инвестицияләрлек бер генә тармак кала инде шулай булгач: тилеләр йорты.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ҖЫЛЫ КИРӘК!

Көз үзенекен итә. Әле кайчан гына өйдә һава җитмәүдән зарлансак, бүген туңабыз. Кайчан җылы бирерләр? Бу көннәрнең иң актуаль соравы шулдыр. Былтыр 16 сентябрьдә җылы бирелгән булса, 2020 елда аны 21 сентябрьдә генә тоташтырганнар.

Татарстан Төзелеш, архитектура һәм коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикадагы 17188 күпфатирлы йортның «әзерлек паспортлары» бар. Бу – барлык йортларның 99,7 проценты кышку чорга әзер дигән сүз. Күп кенә социаль әһәмиятле объектларга җылылык бирелгән дә.

Узган атна ахырында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та, салкыннар җиткәнче, республикадагы барлык объектларны кышка әзерләргә кушты. Бу, беренче чиратта, хастаханәләр, шифаханәләр, мәктәп-бакчалар һәм картлар йортлары, интернатларга кагыла, дип искәртте ул.

– Көз җитте. Һава торышы җылылык кушуны сорый. Кышка әзерләнмәгән объект йә котельный – бик зур проблема. Бу – җаваплы эш. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Шуңа күрә министрлык та, район башлыклары да, салкыннар килгәнче, вакытында җылылык бирүне тәэмин итәргә тиеш, – диде Президент.

Халык туңа. Фатирларына җылылык үзәкләштерелгән система буенча бирелә торган кешеләр бу көннәрдә еш зарлана. «Төнлә бик салкын. Чарасыздан җылыткыч куеп йоклыйбыз. Куркыта да инде, әмма туңасы килми бит», – ди Казанның Имәнлек урамында яшәүче Гөлсу Искәндәрова.

Җылыны кайчан телисең, шунда кушып җибәреп булмый шул. Ярый ла үз җылылык казаның, котельныең булса. Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Искәндәр Гыйниятуллин әйтүенчә, җылылык бирү өчен йортларның әзер булуы кирәк.

– Казанда 5760 йорт кышка әзер. Тагын 160 йортның «әзерлек паспорты» аласы бар. Аларның 38е бу атнада документ эшләрен тәмамлар, дип көтелә. Киләчәктә торак-коммуналь хуҗалыкка бәйле бөтен документларны электрон системага урнаштырырга кирәк. Болай эшләгәндә, тизрәк булачак, – ди ул.

«Чананы – кыштан, арбаны җәйдән әзерлә», – ди безнең халык. Торак-коммуналь өлкәдә эшләүчеләргә май аеннан августка кадәр җылылык челтәрләрен төзекләндерергә, аларны кышкы сезонга әзерләргә вакыт бирелә. Әгәр берәр кимчелек кенә калса да, кышын күңелсезлек көт тә тор! Төзелеш, архитектура һәм коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин сүзләренә караганда, узган ел республикада 3146 котельный, 3 меңнән артык белем бирү оешмасы, 17 мең күпфатирлы йорт, 2 мең сәламәтлек саклау учреждениесен кышка әзерләгәннәр. Ягу сезоны 261 көн дәвам иткән. Челтәрләрдә 2741 авария булган. Шуның 1862 очрагы суга бәйле. Иң күп күңелсезлекләр Казан, Әлмәт, Бөгелмә районнарында килеп чыккан.

Министр сүзләренчә, бүген республикада су челтәрләренең – 33, җылылык челтәрләренең 37 проценты яңартуга мохтаҗ. Ел саен республиканың авария-техник запасы 80 миллион сумга тулылана. Бу акчага кирәкле җиһазлар алына, аварияләрдән соңгы кимчелекләр төзәтелә.

Җылылыкны кайсы очракта кушалар? Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге башкарма директоры Дмитрий Романовка шул сорауны бирдек.

– Әгәр 5 көн дәвамында һава температурасы +8 градус тора икән, йортларга җылылык бирелергә тиеш. Аны бер көндә генә башкармыйлар. Йортларны җылылык белән тәэмин итү ике атнага да сузылырга мөмкин. Әгәр кешеләр температураның +8 градуска кадәр төшкәнен көтәргә теләми икән, җылылык бирүне сорап, «Ачык Казан» системасына гариза язарга тиеш. Әмма аңарчы фатирлардагы батареялар тәртиптәме, аннан су акмыймы икәнен идарәче оешма хезмәткәрләрен чакырып тикшертеп алсыннар, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

P.S: Язма әзерләнеп беткәндә, республиканың 11 районында җылылык бирелгәне билгеле булды. Калганнарның өйләренә җылы 20 сентябрьдә килә башлый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сәяси сәгать

СӘЯСӘТ БЕЛГЕЧЕ ВЛАДИМИР КУТИЛОВ:

«ДӘҮЛӘТ ЯҢАЛЫКЛАРНЫ ҖИТКЕРЕП ТОРЫРГА ТИЕШ»

Без әле кая барабыз? Дөньяданиләр бар? Бу сорауларга җавапны сәясәт белгече, «Теория Дарвина» агентлыгы генераль директоры Владимир КУТИЛОВ белән эзлибез.

:: Соңгы вакытта илдә мобилизация игълан итү тәкъдимнәре еш яңгырый. Нәрсә диган сүз бу? Аерым сәясәтчеләрнең бүгенге кискен вазгыятьтә үзләрен күрсәтеп калу теләгеме, әллә инде шул рәвешле халыкның мөнәсәбәтен ачыкларга тырышумы?

– Россия хакимиятләре махсус хәрби операция (СВО) мәсьәләсендә бик сак адымнар белән хәрәкәт итә. СВОның статусын, тәртибен үзгәртүнең дә, мобилизация игълан итүнең дә җәмгыятьтә ничек кабул ителәсен, нәтиҗәсен тулысынча аңлыйлар дип уйлыйм. Бу мәсьәләдә очраклы белдерүләр була алмый, миңа калса. Сәясәтчеләр махсус хәрби операция темасы ярдәмендә үзләрен күрсәтеп калу белән мавыкмыйлар.

Украина белән каршылыкның озакка сузылуы һәм катлаулы булуы ихтимал. Ике якның хәрбиләре, сәясәтчеләрен тыңласаң, офыкта, ким дигәндә, 2023 ел күренә. Армиядә кайбер хәрби-учет белгечлекләренә кытлык барлыкка килергә мөмкин. Ул чакта инде өлешчә мобилизация котылгысыз булачак.

:: Махсус хәрби операция башланганга 7 ай тулып килә. Бу вакыйгалар җәмгыятьнең кәефенә ничек йогынты ясый? Вакыт барган саен, халык Донбасстан килгән хәбәрләргәияләшеп, битарафлык барлыкка килмиме?

– Ияләшү дә, арыганлык та барлыкка килә. Һәрвакыт басым булганда, ялган хәбәрләр таратылганда бигрәк тә. Беркөнне кешедә, хәбәрләрнең дөрес яки дөрес түгеллеген бәяләмәс өчен, алардан бөтенләй баш тарту теләге барлыкка килә. Шул ук вакытта дәүләт халыкка махсус операция турында хәбәрләрне даими рәвештә җиткереп торырга, аларны иҗтимагый фикер алышуга җәлеп итәргә тиеш. Илдә бөтен көчне һәм мөмкинлекне эшкә җигәргә кирәк булган чакта вакыйгаларга битараф калырга ярамый. Бу очракта икътисадтагы, җитештерүдәге, фәндәге көч һәм мөмкинлекләрне файдалануны күздә тотам.

:: Халык арасында иң еш кабатланган сорау: бу вакыйгалар кайчан бетәчәк? Шулай да кешене күбрәк ни борчый: махсус операциянең нәтиҗәсеме, әллә инде ашарга һәм киенергә, ипотекага түләргә акча җиткерү кебек көнкүреш мәшәкатьләрме?

– Миңа калса, әлегә социаль-икътисади проблемалар иң кискен дәрәҗәгә җитмәде. Икътисади кризис акрын гына дәвам итә, әлегә ул торгынлык рәвешендә. Икътисадтагы хәлләр берничә айдан, бәлки, яз ахырына таба кискенләшергә мөмкин. Хәзер күбрәк тормыштагы киеренкелек һәм стресс аркасында рухи яктан арыганлык йогынты ясыйдыр. Бу исә кешенең бер яктан, мәгълүматтан читләшүенә, икенче яктан, бүгенге тормышын тыныч вакытлар белән чагыштыруына китерә.

:: Алайса, бу очракта җәмгыятьтәге бердәмлекне ничек сакларга? Бу бит – илнең киләчәге дигән сүз. Халык, әйтик, кока-коладан баш тартырга ризамы?

– Миңа калса,ниндидер ризыклардан һәм брендлардан баш тарту тыныч кына узды. Россиядә яшәүчеләр бу хәлне дөрес бәяли алды. Кайбер компанияләр һәм брендларның илдән китүен күпләр безне кимсетү дип кабул итте. Икенче яктан, халык дефицитны, күпләп сатыла торган азык-төлеккә кытлыкны бөтенләй диярлек тоймады. Ничек кенә булмасын, ниндидер кока-коланың җәмгыять бердәмлегенә берниндн дә катнашы юк дип уйламыйм.

Җәмгыятьтәге бердәмлек даими күренеш түгел ул. Ниндидер мәсьәләдә килешү булырга, ә икенчесендә фикер алышу дәвам итәргә мөмкин. Килешү булсын өчен дәүләтнең дә тырышлыгы кирәк.

:: Инде үзебезгә әйләнеп кайтсак, дөньядагы, илдәге вазгыять Татарстанга ничек йогынты ясый? Президентның эшлекле сәфәрләре, очрашулары дәвам итә, яңа килешүләр имзалана. Ил генә түгел, халыкара чаралар уза. Кыенлыкларны җиңелрәк кичерүгә өметме бу?

– Татарстан – зур Россиянең мөһим миссиягә ия төбәге. Рөстәм Миңнеханов чит илдәге партнерлар белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда һәрвакыт актив булды. Көнбатыш санкцияләренә карамастан, Россия глобаль сәяси һәм икътисади бергәлекнең бер өлеше булып кала бирә. Мәдәниятта, сәүдә өлкәсендә һәм сәясәттә элек-электән хезмәттәшлек иткән илләр белән мөнәсәбәтләрне үстерү эшен дәвам иттерәбез. Татарстан исә нык үсешле икътисадка, мөһим тармакларда көчле сәнәгатькә ия булу нәтиҗәсендә кыенлыкларны башка төбәкләргә караганда берникадәр җиңелрәк кичерәчәк.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

АМБАР ТУЛЫ, КЕСӘ... БУШ?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә.

Билгеле булганча, быел республика кырларыннан рекордлы 5,2 миллион тонна уңыш җыеп алынды. Бу – соңгы ун елдагы иң зур күрсәткеч, дип бәяләнә. Соңгы тапкыр Татарстанда мондый мул уңыш 2008 елда теркәлгән. Ул елны республика кырларыннан барлыгы 6 миллион тонна уңыш җыелган. Быелгы урып-җыю барышында иң күп бөртекләләр Тәтеш, Арча һәм Буа районы кырларыннан җыеп алынган. Биредә игенчеләр 200 мең тоннадан артык уңыш алган.

Артык сөенсәң, бәхетең качар, ди халык. Мул уңыш белән шатландырган бәрәкәтле елның да көендергән мәле була. Ашлык күп булган саен, аның бәясе дә түбәнрәк. Быелгы вазгыять исә башка еллардагысын да уздырды. Урып-җыю эше башланугa, бер тонна ашлык бәясе ике-өч тапкыр (!) диярлек: 8–9 мең сумга кадәр төште һәм хәзер дә шул ук дәрәҗәдә саклана. Чагыштыру өчен: узган елның шул ук чорында республикада бер тонна ашлык хакы 15–17 мең сум тирәсендә тирбәлә иде.

Белгечләр ашлык бәясенең шул дәрәҗәдә төшүен быел аның мул булуына бәйләп аңлата. Күп әйбернең кадере булмый бит. Алыпсатарлар да тик ятмый. Ил күләмендә барган вакыйгаларның да тәэсире зур.

– Экспорт пошлиналары коточкыч зур дәрәҗәдә. Ашлык бәяләре төшүгә шул да этәргеч булды. Бүген игенчеләрнең күбесе, ашлыкны кая куйыйм, дип баш вата. Кайбер культураларның үзкыйммәте аны сату бәясеннән дә зуррак бит. Бу арпа белән бодайда бигрәк тә сизелә. Быелгы кебек мул уңыш алу өчен игенчеләр бөтен җанын, хезмәтен генә түгел, кредит акчаларын да кертте бит. Көзен банклар бу акчаны кире кайтаруны таләп итә башлый. Шул сәбәпле, игенчегә тир түгеп үстергән ашлыгын тиен-миенгә сатып җибәрергә туры килә. Бу бит инде – башка сыймый торган хәл, – ди Татарстан Фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе җитәкчесе Камияр Байтимеров.

Ярдәм булачак

Җитәкчелек исә тынычландырырга ашыга. Атна башында Хөкүмәт йортында узган брифингта Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров килеп туган вазгыятьне вакытлы авырлык кына дип бәяләде.

– Урып-җыю вакытында бәяләр кимү ел саен күзәтелә. Бүген илдә ашлык җитәрлек, тәкъдим күп, шуңа шулай килеп чыкты. Ашлыкны саклауга салгач, ел азагына таба аның бәясе барыбер артачак. Күпмегә икәнен әйтә алмыйбыз. Бераз сабыр итәргә, сату урынын эзләргә кирәк. Экспорт буенча да эшне алып барабыз. Иран юнәлешен карыйбыз. Әле күптән түгел безнең делегация шунда булып кайтты, – диде министр.

Марат Җәббаров, әйтелгәннәр буш сүз генә булып калмасын дип булса кирәк, ашлык бәяләрен җайга салачак чараларны да санады. Бүгенге вазгыятьне исәпкә алып, Россия хөкүмәте, субсидияләтә кайтару өчен, Резерв фондыннан өстәмә акча бүлеп бирү турында карар кабул иткән. Бу ярдәмне алу өчен, хуҗалыклар «Зерно» федераль системасында теркәлгән булырга тиеш. «Бу максатка барлыгы 1,3 миллиард сумнан артык акча бүлеп биреләчәк. Акчаны быел дүртенче кварталда бирү планлаштырыла», – диде Җәббаров.

Министр сүзләренә караганда, дәүләт Ашлык фондына Татарстаннан 300 мең тонна ашлык сатып алачаклар. Бу да, үз чиратында, бәяләрне җайга салырга ярдәм итәр, дип көтәләр.

Берәү ала, берәү сабыр итә

Марат Җәббаров фикеренчә, килеп туган вазгыятьнең уңай ягын да күрә белергә кирәк. Бүген республиканың терлекчелек тармагында 3 миллион тоннадан артык ашлык кулланыла. «Терлекчелек һәм кошчылык белән шөгыльләнүчеләр өчен бик отышлы вакыт хәзер. Ел буена җитәрлек ашлыкны бик түбән бәядән алып куя алалар», – ди ул.

Күпләр шулай эшли дә. Буада яшәүче Азат Гыйльфанов әти-әнисенә ике тонна ашлык алып кайтып биргән. Килосын 8 сумнан эләктереп кала алганына сөенә ул. «Авылда бозаулар асрыйбыз. Әти-әнинең малларны бетерәсе килми әле. Өстәвенә быел ашлык бәяләре дә бик түбән. Аны арзанга алып калганыма шатланам. Әле тагын кирәк», – ди ул.

Балтач районы Куныр авылында яшәүче Шәрәфетдиновлар да берничә көн элек кенә 11 сумнан ике тонна арпа алган. «Алуын алдык та, ашыктык, ахры, бераз сабыр итәсе булган, дибез. Соңрак очсызрак та булыр иде. Ел саен шушы вакытта сатып бетерә алмаган ашлыкның бәясен төшереп саталар бит. Ярар инде, китереп бирделәр, шунысы сөенеч», – ди Гөлшат Шәрәфетдинова.

Кыска хәтер бәласе

Белгечләр исә, хәзер ашлык алып калу өчен нәкъ вакыты, дип искәртә. Актаныш районының «Нигез» хуҗалыгы җитәкчесе Дамир Җәлилов та шул фикердә. «Аласы булса, ашлыкны хәзер алырга кирәк. Бүген аның иң отышлы чагы инде. Бер айдан бәясе барыбер күпмедер артачак. Фермерларның сугып алган, иләнмәгән, чистартылмаган ашлыклары да бетәчәк. Аның бәясенең ничек булып бетәчәген төгәл генә фаразлап булмый бүген. Декабрьдә, гыйнварда артырмы – билгесез. Россиядән ашлык чыгарырга рөхсәт булырмы? Булмаса, бәясе дә артмаячак дигән сүз», – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

«Нигез» хуҗалыгында уңышны тулысынча җыеп бетергәннәр. Быел республикада иң күп уңыш җыеп алган хуҗалыкларның беренче унлыгына ук (таблицада – **Д.Г.**) кергән алар. Гектарыннан 58,1 центнер уңыш чыккан. Бүген хуҗалыкта яңа склад төзеп яталар. Элеватордагы ашлыкны шунда алып кайтып урнаштырачаклар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Булганына шөкер итә белергә кирәк. 35 еллык эш стажымнан чыгып шуны әйтә алам: авыл хуҗалыгында алдагы елда әйбәтрәк булыр әле, дип гомер үтте безнең. Әмма алай булмады һәм булмас та инде. Безнең илдә хәтер кыска: юк чагында бөтенебез дә күккә күтәреп сөйлибез. Булганда кадере юк. Әмма аңа карап, борын салындырырга җыенмыйбыз. Шөкер, терлекләребез бар. Терлекчелек продукциясе аша булса да без аны барыбер әрәм-шәрәм итмибез, Алла боерса, – ди Дамир Җәлилов.

Үзләреннән генә тормаган әйберләрнең дә уңай хәл ителәчәгенә өметләнә ул. Чәчелгән көзге культураларның тишелә алмыйча утыруларына эче поша җитәкченең. Җиргә ике ай ярымнан бирле бер тамчы яңгыр төшкәне юк икән.

Арадашчыга җәл

Балтач районының «Арбор» хуҗалыгында да түземсезлек белән яңгыр көтәләр. Хуҗалык җитәкчесе Хәмит Баязитов быелгы уңышка шөкер итә. «Быел өметләр акланды. Уңышны исән-сау гына җыеп бетердек. Эшкәртеп, салып та куйдык инде. Уңыш мул елны ашлыкның бәясе түбән булу гына кызганыч», – ди ул.

«Арбор» хуҗалыгында әлегә ашлыкны сатмыйлар, саклап торалар икән. Бәясе, ким дигәндә, 12 сумга кадәр күтәрелгәч, сата башларбыз дип торалар биредә. Аны элеваторга да тапшырмыйлар. Складта урыннар бар, курка торган түгел. Алыпсатарлар ашлык сорап килә башлаган инде. Әмма шундый көч түгеп алган уңышны юк-бар бәягә җибәреп булмый, билгеле.

– Ашлыкның үзкыйммәте дә югары бит инде. Ягулык-майлау материаллары бәясе артты, ашламалар инде ике-өч ел эчендә өч тапкыр кыйммәтләнде. Эшчеләргә хезмәт хакы түлисе, техниканы да яңартасы бар. Болар да ашлыкның үзкыйммәтенә йогынты ясый бит. Булыр әле. Бәлки, ашлык бәясе артып китәр. Бар да аны чит илгә чыгара алмауга бәйле бит инде. Юллары ачылса, вазгыять тә җайланыр иде, – ди Хәмит Баязитов.

Хуҗалык җитәкчесе ашлык бәяләренең яңа елга кадәр артуына өметләнә. «Көньяктагы портларда бәяләр 12–14 сумга җиткән, дип сөйләшәләр. Безгә дә кыйммәтләнгәнне озак көтәсе калмагандыр», – ди ул.

Акча бүген кирәк

Әгерҗе районындагы крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Илнур Сәетов, алдагы елларда да бүгенге хәлләр кабатланса, күпләр җир эшен ташлаячак яки башка төр культуралар чәчә башлаячак, дигән фикердә.

– Быел өметләр акланмады, чөнки уңышы бар, бәясе юк. Мондый зур уңышка караганда, уртача уңыш әйбәтрәк. Ашлык бәясе әле һаман 7–8 сумнан артмый. Аның бәясе булмау – дәүләткә, базарга безнең ашлык кирәкми дигән сүз. Дөнья күләмендә ашлык бәясе әйбәт ул. Бодайның бер тоннасы 300 евро чамасы йөри. Безнең акчага әйләндергәч, 18 сум тирәсе була. Безгә аның кадәр үк түгел, 13–14 сум булса да яхшы булыр иде әле, – ди Илнур.

Тәҗрибәле фермер бүген кырлардан җыеп алган ашлыкның бер өлешен саткан инде. Аны 8 сумнан җибәргән. Башкача булмый, сатмасаң, сакларга да кирәк бит әле. Илнур Сәетов хуҗалыгында җыелган ашлыкның бер өлеше хәзергә саклауга куелган, күпмедер өлеше элеваторда ята. Фермерлык белән 2005 елдан бирле шөгыльләнә ул. Булган ашлыкның тиешенчә бәяләнмәвен дә беренче тапкыр гына күрүе түгел.

– 2017 елда ашлык бәясе 5 сумга кадәр төшкән иде. Әмма ул вакытта аның үзкыйммәте дә азрак булды. Хәзер бит бар нәрсәнең бәясе артты. Орлык, ягулык, ашлама, агулар – барысы да кыйммәтләнде. Техниканы әйтәсе дә юк. Ашлыкны сатмый торыгыз, сабыр итегез, диләр. Алай гына булмый бит ул. Күп кеше кредит алган. Хәзер чәчүне дә алып барасы бар. Ул акча бит бүген кирәк. Көтеп торырга вакыт юк, – ди Илнур.

Якын арада ашлык бәясе 12–13 сумга күтәрелсә, бик яхшы булыр иде, дип өметләнә фермер. Быелгы вазгыять аркасында, киләчәккә планнарын да үзгәртергә туры килгән аңа. «Киләсе елга хуҗалыкны җәелдерермен дип уйлаган идем, сабыр итәргә булдым әле», – ди Илнур Сәетов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ИҢ КҮП УҢЫШ ҖЫЙГАН ХУҖАЛЫКЛАР

Район	Хуҗалык	Уңыш (ц/гектар)
Тукай	«Ирек» җитештерү кооперативы» ҖЧҖ	82,1
Тукай	«Гигант» ҖЧҖ	76,2
Тәтеш	«Колос» агрофирмасы» ҖЧҖ	71,3
Тәтеш	«Бакырчы» ҖЧҖ	68,8
Биектау	«Битаман» ҖЧҖ	63,0
Чүпрәле	«Цильна» ҖЧҖ	62,0
Тукай районы	«Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» ҖЧҖ	59,5
Саба	Мөхәммәтшин З.З. крестьян-фермер хуҗалыгы	59,0
Тәтеш	Сафиуллова Р.Г. крестьян-фермер хуҗалыгы	58,1
Актаныш	«Нигез» ҖЧҖ	58,1

23 сентябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Чулпан Гарифуллина** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Эшләүче пенсионерга нәрсә тиеш?

Эшләүче пенсионер эштән туктаса, аңа өстәмә түләүләр гариза биргән көннән исәпләнәме? Әллә инде бу акча 3 айдан соң гына килә башлыймы? Узган 3 айныкы дүртенче айныкына кушып биреләме? Эштән туктаган пенсионер кабат эшкә урнашырга теләсә, элек эшләп туктаган вакыттан соң 3 ай вакыт көтәргә кирәкме, әллә 1 ай булса да җитәме?

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ, хезмәт ветераны. Азнакай

Россия Пенсия фондының Татарстан идарәсенең матбугат җитәкчесе Альбина Никандрова:
– Пенсионерның пенсиясе эштән киткәннән соң икенче айдан индексацияләнә. Пенсионерның эшләгән чорындагы барлык индексацияләрдән чыгып, пенсия күләме арта. Эштән китеп, 3 ай узганнан соң гына сезгә пенсиягез артып һәм берьюлы 3 ай өчен өстәмә түләнәчәк. Яңа пенсия күләме пенсионер янә эшкә урнашкан очракта да сакланып калачак.

pixabay.com

Ташландык бакчаларны нишләтергә?

Безнең бакчачылык җәмгыятендә ташландык бакчалар шундый күп. Этләр дә ияләшә, янгын чыгу куркынычы да арта. Аларны нишләтергә мөмкин икән?

Сабир ХӘСӘНОВ. Казан

Никита Чаплин, Россия Дәүләт Думасы депутаты:
– Башта ташландык бакчаның кемнеке икәнлеген ачыкларга кирәк. Әгәр хуҗасы үлсә, варислары булмаса, аны сатарга мөмкин. Әмма милекче исән-сау икән, закон буенча бу бакчага тияргә ярамый. Депутатлар бу проблеманы хәл итү юлларын эзлиләр. Хуҗасы булган, әмма ташландыкка әйләнгән бакчаларны «файдаланылмыйча ятучы» итеп рәсмиләштерү өчен документлар әзерләнә. Әйтергә кирәк, хуҗасыз участоклар гына түгел, хәтта тулаем хуҗасыз калган бакчалар да бар. Быел хөкүмәтебезнең июль аенда кабул ителгән 217 нче законы мондый бакчачылыктагы участокларны башка оешмаларга бирергә рөхсәт итә. Әмма мондый практика эшләп китә алмый әле. Россия бакчачылары берлегендәге мәгълүматларга караганда, илебездә бакчачылыктагы җирләрнең 10–15 проценты ташландык хәлдә. Кайбер төбәкләрдә бу сан 50 процентка җитә.

Кишерне кайчан чәчәсе?

Күп кенә бакчачылар кишерне дә көздән чәчеп калдыра. Аның билгеле бер сортларын гына утыртырга ярыймы һәм аны кайчан чәчәсе?

Галинур ИМАМОВ. Сарман

Эльмира Исхакова, һәвәскәр бакчачы:
– Кишер орлыгын сатып алганда, кабына игътибар белән карагыз: анда көздән чәчәргә ярый дигән билге торырга тиеш. Иртә өлгерешле сортлары да була. Аларны июньдә үк ашый аласыз. Урта өлгерешлесеннән салатлар ясарга яки, угычтан уып, суыткычка кышка туңдырып куярга мөмкин. Аларны базда саклап булмый. Ә минә «Королева осени» дигән сорт – иң отышлысы. Береннчедән, суыкка чыдам, икенчедән, җитешү вакыты да – 130 көн. Көздән утыртсагыз да, кышка сакларга әйбәт.

Кишер утыртасы түтәлне алдан әзерләп куегыз. Ел саен урынын алмаштырырга кирәк. Быел утыртып уңыш алган түтәлгә өч-дүрт елдан соң гына әйләнеп кайтырга кирәк. Кишерне суган, сарымсак, бәрәңге, помидор, кыяр, кабак, ташкабак, кәбестә үскән урынга утыртсаң яхшы. Түтәленә черемә, көл салып, казып әзерләп куегыз. Чүпләрдән арындырыгыз. Әзер түтәлне пленка белән каплап куегыз. Орлык өстенә сибәсе туфракны җир коры вакытта алып калыгыз. Ул җылыда торырга тиеш. Һава температурасы –2 градуска төшкәч, орлыкны чәчәргә дә була. Күе итеп чәчегез, чөнки ничек тишеләсен белеп булмый. Чәчкәч, орлык өстенә җылыда торган туфракны сибеп чыгасыз. Җирен бераз тыгызлап куясыз һәм өстенә чыршы ботаклары ябасыз.

Ашта оекбаш өләшү дөресме?

Корьән мәҗлесләрендә, ашларда сәдака тарату гадәте каян килеп чыккан икән? Бер караганда, табын янында утыручыларның берсе дә сәдака иясе түгел бит. Тагын бер соравым бар иде. Сәдаканы акчалата бирүме, әллә, соңгы вакытта еш күзәтелгәнчә, оекбаш, сабын, чынаяклар белән бирү дөресрәкме?

Галимә МОРТАЗИНА

Алмаз хәзрәт Сафин, «Өметлеләр» мәчете имам-хатыйбы:
– Безнең җирлектә Корьән мәҗлесендә хәер һәм бүләк өләшү гадәте бар. Бу – мөстәхәб-саваплы гамәл. Сәдака бирсәң, әҗер-савапка ирешәсең, ә бирмәсәң, гөнаһлы булмыйсың. Бәлки элекке вакытта мондый мәҗлесләргә фәкыйрьләрне, ятим балаларны, мескеннәрне җыеп, сәдака таратканнардыр һәм бу гамәл тора-бара гореф-гадәткә әйләнгәндер. Асыл сәбәбен бер Аллаһ белүче. Әгәр дә табын янында утыручылар сәдака иясе булмаса, аларга таратырга теләгән нәрсәне бүләк нияте белән бирәсең.

Ә сәдаканы акчалатамы, әллә инде әйберләтәме дигәндә, аларның икесе дә рөхсәт ителә. Иң мөһиме – сәдака итеп таратылган нәрсәдән кеше файда күрсен һәм көнкүрештә куллана алсын. Дини ашларда акча урынына көндәлек тормышта куллана торган сабын, оекбаш, чәй, савыт-саба, китап, кулъяулык кебек әйберләрне тарату шулай ук хәерле

Рәхмәт ишетү рәхәт

Җәй көне авырып киттем. Хәлем бик начар иде. Мине «ашыгыч ярдәм» машинасы белән Казанның 6 нчы хастаханәсенә алып киттеләр. Гемоглобиным төшеп беткән булган. Анда бик яхшы табибларга туры килдем. Күп еллар бирердә эшләүче табиб Рафаэль Минабутдиновка туры килүем белән тиз савыктым. Өч көн дигәндә, ул мине аякка бастырды. Тикмәгә генә авырулар аны «Ходай юлаган табиб» димиләр икән. Ул табиб турында нинди сүзләр әйтсәм дә, аз булыр кебек. Сезнең газетагыз аша Рафаэль Минабутдиновка һәм аның янында эшләүче егеткызларга чиксез рәхмәтемне белдерәм.

РЕЗЕДА. Казан

Тәкъдим

Бервакыт шулай Зәй шәһәрендә йөри торган рейс автобусында кайтып барам. Тукталышлар арасы бик озын. Бер әби хастаханәдән чыккан, хәле авыррак күренә. Үз йорты янында төшеп каласы килә моның. Йөртүчедән үтенеп сорый. Тик ул ризалык бирми. Дөрес эшли инде, ярамагач, кагыйдәләрне боза алмый. Бу җәһәттән минем бер тәкъдимем бар иде. Кайбер кешеләрнең кулларында документлар да бар бит. Авыррак хәлдәгеләрен, чыннан да, тукталыш булмаса да, кирәкле урыннарында төшереп калдыра алырга мөмкинлек тудырмаслармы икән? Депутатлар утырышларда шул мәсьәләне карасыннар иде.

Әнвәр ӘХМӘТБАЕВ. Зәй

гамәлләрдән санала. Әгәр дә ул аны ихлас ният белән эшләсә, сәдака өләшүче кешегә аның өчен әҗер-савап языла.

Бал ашарга ярыймы?

Чәйне гел бал белән яратып эчә идем. Быел әллә нәрсә булды әле: аллергия башланды. Хәзер балны куллана алмаммы икән инде?

РӘМЗИЯ. Балык Бистәсе

Юлия Миневич, табиб-аллерголог:
– Сүз дә юк, бал бик файдалы. Шуңа күрә һәр кеше кышка запаска алып калырга тырыша. Ул бит ризык пешергәндә дә, косметикада да, халык медицинасында да кулланыла. Антибиотик буларак та файдасы күп. Әмма кайбер очракларда, чыннан да, балдан ваз кичәргә туры килә. Балның организм өчен куркыныч чаклары да була. Мәсәлән, аны бер яше тулмаган балаларга бирү катгый тыела. Бактерияләр баланың эчәклекләрендә үрчеп ятарга һәм куркыныч токсин эшләп чыгарырга мөмкин. Аллергия булган кешеләргә дә бал ашарга ярамый. Ул тулаем балга түгел, ә бәлки аның составындагы билгеле бер компонентларга, аерым алганда, серкәгә булырга мөмкин. Нәтиҗәдә бик җитди чирләр килеп чыгуы бар, кайбер очракларда үлем очраклары булганын да әйтеп үтәргә кирәк. Аллергия булганда, суларга һава җитми башлый, баш әйләнә, косасы килә, хәл бетә, тир бүленеп чыга башлый, кеше аңын җуеп егылырга да мөмкин. Бигрәк тә йөрәк эшчәнлегенә тәэсир итү куркынычы бик кискен. Шикәр авыруыннан җәфаланган кешеләр дә балдан ваз кичеп торсын иде. Канда шикәр күләме арту куркынычы бар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

Укучы сүзе

«КУРКУ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Риман абый, бик яратып укыйм сезнең язмаларны «Ватаным Татарстан»да. Без дә әле 2 ел гына өйдә утырабыз. Әле генә бер-беребезне күргән кебек.

Әсфәния ГАЛӘҮТДИНОВА

* * *

Риман абый, бик яратып укыйм язмаларыгызны. «Ватаным Татарстан»ны сезнең язмадан укый башлыйм. Сәламәт, тигез, тыныч, мул, матур яшәгез. Амин.

Миләүшә МИНАЕВА

* * *

Мин дә ушым китеп укыдым… Вәт дөрес язылган бит, әмма пар канатлы булып картаерга һәркемгә дә насыйп булмый шул. Бәхетле, парлы картлык насыйп итсен.

Рәмзия ИСМӘГЫЙЛОВА

«АВЫЛ ШӘҺӘРГӘ КИЛДЕ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Түбән Камада нишләп алай кыйбат? Нишләп әзрәк тикшермиләр икән ул бәяләрне?

Рәйсә ИДРИСОВА

* * *

Үзегез бакчагызны яздан сөрдереп, утыртып, җәй буе суын сибеп, карап, 3–4 тапкыр утап, бәрәңге булса, дарулар сибеп, көз җиткәч чыгарып, транспорт табып, ярминкәгә чаклы алып барып, чыккан чыгымнарны санарга онытмыйча, алган орлыкларыгызны да кушып… Йә, нинди хак белән сатар идегез?

Гөлфия ГАФАРОВА

* * *

Үзе эшләп карамаган кешегә шулай тоела, күрәсең, бик дөрес сүзләр. Эшләп ашасыннар – очсыз да, тәмле дә була. Менә без – авыл кешесенә юк ул ярминкәләр, килсеннәр иде әле. Юнь бәягә иләктер, чиләктер сатарга.

Минниса САБИРОВА

19 сентябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим русский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». 6+
00.15 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 19.35, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Асыл Нури». Шагыйрь Нури Арсланов 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «Асыл Нури». Шагыйрь Нури Арсланов 6+
19.10, 21.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
23.05 «Башваткыч» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «МОСГАЗ. ДЕЛО №8: ЗАПАДНЯ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Михаил Пореченков, Александра Богданова, Равшана Куркова, Юрий Чурсин, Николай Добрынин, Юлия Галкина, Юлия Мельникова. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.50 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР!-2» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 09.10, 12.35, 14.45, 21.55 Новости
06.05, 19.15, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 04.50 Специальный репортаж 12+
09.35 «НА ВСЕХ ШИРОТАХ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 14.50 «ШАОЛИНЬ» 12+
15.50 «Громко» Прямой эфир
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Трактор» (Челябинск) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
19.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Кубань» (Краснодар) – «Арсенал» (Тула). Прямая трансляция
22.45 Тотальный футбол 12+
23.15 «КРОВЬЮ И ПОТОМ: АНАБОЛИКИ» 16+
01.55 «Четыре мушкетёра». Док. фильм 12+
02.55 Новости 0+
03.00 «АГЕНТ» 16+
05.05 «Громко» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Олег Штефанко. «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Никита Панфилов в остросюжетном сериале «ЛИХАЧ» (S) 16+
21.45 Премьера. Вахтанг Беридзе, Андрей Градов. «СТАЯ» (S) 16+
00.00 Константин Юшкевич. «БАЛАБОЛ» (S) 16+
01.45 Остросюжетный сериал. «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Самое дорогое» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.50 «ЖЕРТВА ЛЮБВИ». 1-я - 4-я серии 16+
19.00 «ОБОРВАННАЯ МЕЛОДИЯ» 16+
22.35 «Порча». «Пустая память». «Рай в шалаше» 16+
23.40 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.45 «Понять. Простить» 16+
01.40 «Тест на отцовство» 16+
03.20 «Давай разведёмся!» 16+
04.10 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.00 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
04.45 «НА БЕЗЫМЯННОЙ ВЫСОТЕ» 16+
06.30 «19 сентября – День оружейника». Док. фильм. Премьера! 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «ЭКЗАМЕН» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Зенитные ракетные комплексы. С-75 против «Найк-Аякс». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Жизнь по легенде. Судьба разведчика-нелегала» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
01.05 «ДЕРЗОСТЬ» 12+
02.40 «Легендарные самолеты. Истребители Як». Док. фильм 16+
03.25 «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА» 16+

20 сентябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2» 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Телефильмы. Старик Державин и за доставленные хлопоты прошу извинить. А.Пешков 12+
00.45 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.10 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «Җырлап яшик, туганнарым!» Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев концерты 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.25 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Бормалы су. Заһид Хәбибуллин» 12+
22.20 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
00.15 «Ватандашлар» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «МОСГАЗ. ДЕЛО №8: ЗАПАДНЯ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Михаил Пореченков, Александра Богданова, Равшана Куркова, Юрий Чурсин, Николай Добрынин, Юлия Галкина, Юлия Мельникова. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.50 «СРОЧНО В НОМЕР!- 2» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 09.10, 12.35, 14.45, 21.55 Новости
06.05, 15.35, 18.45, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.40, 04.50 Специальный репортаж 12+
09.35 «НА ВСЕХ ШИРОТАХ» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 14.50 «ПОЕЗД НА ЮМУ» 16+
16.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Барыс» (Нур-Султан) – «Автомобилист» (Екатеринбург). Прямая трансляция
19.25 «13 УБИЙЦ» 16+
22.00 Профессиональный бокс. Андрей Сироткин против Абилхайыра Шегалиева. Прямая трансляция из Москвы
00.50 Смешанные единоборства. UFC. Колби Ковингтон против Тайрона Вудли. Хамзат Чимаев против Джеральда Меершафта. Трансляция из США 16+
01.55 «Один за пятерых». Док. фильм 6+
02.55 Новости 0+
03.00 «АГЕНТ» 16+
05.05 «Правила игры» 12+
05.30 «Человек из футбола» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ЛИХАЧ» (S) 16+
21.45 Премьера. «СТАЯ» (S) 16+
00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
01.45 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Воронка» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.50 «ЖЕРТВА ЛЮБВИ». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «ОНА, ОН И ОНА» 16+
22.50 «Порча». «Смертельное наследство». «Чудовище» 16+
23.55 «Знахарка» 16+
00.30 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.55 «Тест на отцовство» 16+
03.35 «Давай разведёмся!» 16+
04.25 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «В НОЧЬ НА 20-е» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Зенитные ракетные комплексы. С-200 против «Найк Геркулес». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.50 «НА ВОЙНЕ КАК НА ВОЙНЕ» 12+
02.20 «Живые строки войны». Док. фильм 12+
02.50 «Калашников». Док. фильм 12+
03.20 «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 19–25 СЕНТЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Плансыз-нисез эшли һәм яши торган бер кеше белән якыннан танышып, бу дөньяда шулай рәхәтрәк икән, дигән нәтиҗәгә килерсез. Күңелегезнең хисле чагы: көтмәгәндә генә гашыйк булып куярсыз. Эштә әйбәт яңалыклар ишетеп куанырсыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Соңгы вакытларда шактый зур кыенлыклар аша узарга туры килдеме? Алары онытып, иркен сулап куяр чак. Җилдән килгән җилгә китәр, дигән гыйбарәне искә төшерерсез.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Хезмәттәшләрегез белән аралашканда, бер хәбәр ишетеп, хәйран калырсыз. Гаиләгездә бик бәхетле мизгелләр кичерерсез. Атна ахырында уйланырга мәҗбүр иткән вакыйга шаһитына әйләнерсез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Сезгә үзегезнең кечкенә генә кабырчыгыгызда яшәү ошый. Шулаймы? Ләкин бу атнада аннан чыгарга туры килер. Борчыласы юк: бик уңышлы булачак ул. Кирәкле кешеләр белән якынаеп китү генә ни тора!

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Сөйкемлелегегез тагын да артыр. Ә бу моңарчы һаман «киреләнеп» торган эшләрегезнең, ниһаять, көйләнеп китүенә китерер. Атна ахырында рәхәтләнеп күңел ачу өчен әйбәт кенә форсат чыгар.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Дусларыгыз арасыннан берсе күңелегезне күтәреп җибәрердәй хәбәрләр ирештерер. Атна уртасында керемгә бәйле шәп яңалыклар ишетелер. Ләкин төннәрендә күңелегезне рәхәт кенә кытыклап алырдай хәлләр булып алыр.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Яңа эш урыны тәкъдим итеп, күңелегезне алгысытып куярлар. Ләкин бу адымга барганчы, алдын-артын ныклап уйларга кирәк. Без булмаган җирдә яхшы, диләрме әле?

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бөтен тырышлыкны өегезне ямьләндерү, күркәмләндерүгә куярсыз. Керемегез арту шәп кенә йорт кирәк-яраклары сатып алу мөмкинлеге дә бирер. Инде килеп, гаиләдәге мөнәсәбәтләр моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә җылыныр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Сөеклегез үзен искиткеч әйбәт яктан күрсәтеп, сезне үлеп яратуын тагын бер кат расларь. Хезмәт урынында бөтен көчегезне биреп эшләү тикмәгә булмас: җитәкчегез эш хакын күтәрер. Гомумән, сез бу атнада финиш сызыгын беренче булып кисеп чыгучыга әйләнерсез.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Романтик дулкынга көйләнерсез. Бәрхет сезонында җылы диңгез буенда кызыну әйбәт булыр анысы, тик гаиләләргә генә мең дә бер проблема китереп чыгарырга мөмкин ул…

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Атна башында эштә килеп чыккан бер вакыйга үзегезнең күпләрдән акыллырак икәнегезне күрсәтер. Беркемгә, хәтта якыннарыгызга да ачылып китмәгез: дөрес аңламаулары бар. Бер мәсьәләдә алтын урталыкны табып, балаларча сөенерсез.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Кызыклы кешеләр белән очрашулар көтегез. Абруегызның үсүе керемегез артуга китерер. Гаиләгездәге проблемаларга игътибарлы булыгыз, юкса тавыш чыгарга мөмкин.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексына югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең гомуми игенчелек, үсемлекләрне саклау һәм селекция кафедрасы мөдире **Сафин** Радик Ильяс улы; республиканың финанс системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты оператив контроль бүлеге башлыгы **Солнцева** Лилия Андреевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Җәмгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының махсус техник чаралар бюросы башлыгы урынбасары – бүронең 7 бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Сабиров** Рөстәм Галимҗан улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең агро-биотехнологияләр һәм җирдән файдалану институты директоры **Серҗанов** Игорь Михайлович **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӘЙЛӘНМӘСЕН АГУГА

Каш ясыйм дип күз чыкмасын! Сәламәтлекне ныгытам дип күпләп витамин эчү белән мавыгучыларны белгечләр шулай дип кисәтә. Чама хисен югалтсаң, витамин да агуга әйләнергә мөмкин, ди алар. Витаминнарны чамасыз куллану бигрәк тә нәрсәсе белән куркыныч?

Казан шәһәренең Тимерьюлчылар поликлиникасының гомуми практика табибы Гөлнара ВӘЛИУЛЛИНА шул хакта сөйләде.

● Соңгы арада халык сәламәтлекне, иммунитетны ныгытуга аеруча игътибар итә. Күпләр бу максатта төрле биологик актив кушылмалар (БАД), витаминнарга өстенлек бирә. Аларны, табиб белән киңәшләшмичә, үз белдеклеге белән кулланучылар шактый. Әмма бу бик куркыныч. Файдалы матдә һәм витаминнарның организмга чамадан тыш күп керүе (гипервитаминоз) аркасында кешедә яңа чирләр пәйда булырга мөмкин. Мисал өчен, тимерне артык күп кулланган кеше Альцгеймер һәм Паркинсон кебек картлык авыруларына тизрәк бирешә.

● Көзге чорда С витаминына өстенлек бирәбез. Ник дигәндә, ул элек-электән вируслы авыруларга, соңгы елларда хәтта коронавируска да каршы торырга ярдәм итүче витамин санала. Әмма чама хисен югалткан очракта, ул да организмга зыян гына салачак. Даими рәвештә С витамины эчкән кеше организмында B_{12} витамины авырдан үзләштерелә башлый, бәвелдә бәвел кислотасы күләме арта. Бу исә үз чиратында бөергә таш утыруга китерә, кандагы эстрогеннар (хатын-кыз гормоны) күләмен арттыра.

● Ашказаны-эчәк тракты эшчәнлеге бозылу – витамин, БАДларны чамадан тыш, бигрәк тә ач карынга кулланган очракта күзәтелә торган иң беренче билге. Андый чакта кешенең күңеле болгана, косасы килә, эче йомшара. Шуңа күрә витаминнар эчә башлагач, алда телгә алган билгеләрнең берсе генә күзәтелсә дә, табиб белән киңәшләшү хәерле.

● А витамины белән мавыккан кешенең тора-бара бик нык чәче коела башлый. Әлеге витаминның бер өлеше майга әверелә. Шуңа күрә А витаминын чамадан тыш куллану аркасында кеше артык авырлыктан да интегергә мөмкин.

● Ябыгу максатында төрле биологик актив матдәләр эчкән кешенең йөрәк тибеше бозыла. Ник дигәндә, күп кенә БАДларның составында йөрәк тибешен тизләтүче стимуляторлар була. Алар белән мавыккан кешенең даими рәвештә башы әйләнергә, кан басымы күтәрелергә мөмкин.

● БАДлар – бавыр өчен дә зур сынау. Алар бавырдагы ферментлар күләмен арттыра. Бу исә үз чиратында бавыр эшчәнлеге бозылуга, гепатитка китерергә мөмкин. Шуңа күрә БАДлар кулланыр алдыннан иң беренче чиратта бавырны тикшертергә кирәк.

● Күп кенә витаминнар, биологик актив кушылмалар канны сыегайта. Шуңа күрә аларны чамасыз кулланган очракта кан китәргә мөмкин. Әйтик, К витаминын тромбка каршы билгеләнгән антикоагулянтлар белән бергә эчкән очракта, кан үзеннән-үзе сыегаячак. Е витамины да кан китү ихтималын бермә-бер арттыра.

НИНДИ ВИТАМИН ҖИТМИ?

Җитмәгән витамин төре	Нинди билгеләр күзәтелә?	Кайдан табарга?
А витамины	күз күрүе начарлана, күз кабагы кычыта, тән кытыршылана, чәч төсе тоныклана, тешләр саргая	сөт ризыклары, диңгез ризыклары, карлыган, крыжовник, абрикос, кишер, шпинат
B_1 витамины	тән тиресе җыерчыклана, тын кысыла, аппетит начарлана, аритмия	чүпрә, камыр ризыклары
С витамины	теш казналыгы каный, кариес пәйда була, сулыш алу кыенлаша, ашкайнату системасы начар эшли башлый, хәлсезлек сизелә, кеше тиз арый	яшелчә, җиләк-җимешләр, кара карлыган, томат, шпинат
D витамины	кариес пәйда була, буыннар авырта, тәнне көзән җыера, кеше ябыга	бавыр, йомырка, сөт ризыклары, майлы балык
Е витамины	организм тизрәк картая, тән тиресе «шиңә», күз күреме начарлана	йомырка, кәбестә, шпинат, кишер, зәйтүн мае, көнҗет, җитен мае, миләш, сырганак, балык мае, чикләвек
К витамины	тән тиресе аз гына җәрәхәтләнсә дә, көчле кан ага, теш казналыклары каный, ашкайнату системасы бозыла, хәлсезлек сизелә	Кәбестә, брокколи, шпинат

КАБАКНЫҢ МЕҢ ШИФАСЫ

Бакчада ут янып утырган кабакның шифасы әйтеп бетергесез. Аның йомшагында, төшләрендә сәламәтлекне ныгытырга ярдәм итүче ферментлар, җиңел үзләштерелүче углеводлар, аксым, җепселле тукыма һәм пектиннар, сахароза, табигый кислоталар бар. Кабак фосфор, кремний тозлары, бакыр, В, С витаминнарына да бай. Ул ашказаны эшчәнлеген яхшырта, эч кибүне булдырмый.

Кабакның йомшагы һәм төшләре шикәр авыруы булганда, үт куыгы, бөер тукымасы, ашказаны, нечкә һәм туры эчәк ялкынсынганда, тоз утыру авыруы күзәтелгәндә, йокысызлыктан интеккәндә ярдәм итә. Тән өшегәндә, пешкәндә, тире кызару авыруы күзәтелгәндә, яралар һәм шешле куыкчыклар булганда, кабакны уып, җәрәхәтле урынга куйсаң, ярдәм итми калмас.

Бөердәге таштан. Кабак суының бөерләрдән вак ташларны һәм комны чыгаруы фәнни яктан дәлилләнгән. Кабак суы ялкынсынуны киметә, сусауны баса, бәвел кудыра.

Суалчаннарны бетерү өчен. Киптереп чистартылган 300 г кабак төшен яхшылап изегез, бал яисә кайнатма өстәгез. Бу катнашманы (1 сәгать дәвамында) ач карынга ашагыз.

Үт куыгы ялкынсынган вакытта. Үт куыгы һәм бавыр ялкынсынганда «кабак сөте» эчү файдалы. Аны җиңел генә әзерләргә була. 50 г чистартылган төшкә су (80 мл) һәм шикәр комы (20 г) салып изегез. Аннары файдалы «сөт»не ач карынга эчегез.

Авыру бавырга кабак орлыклары төнәтмәсе дә ярдәм итәр. 250–500 г орлыкка 0,5–1 л кайнар су салып, 2 сәгать төнәтегез. Төнәтмәне 1 сәгать дәвамында эчегез.

Яшәеш сәгате

Галимнәр, тәүлек дәвамындагы эшчәнлегеңне вакыт ритмнарына яраштырып алып барырга кирәк, диләр.

pixabay.com

1.00 Бу вакытта эшләүнең дә, укуның да файдасы юк, чөнки баш мие бернинди эшкә дә сәләтле түгел.

5.00 Бу вакытта ир-атларның тестостерон гормоннары күп эшләнеп чыга. Матдәләр алмашы да көчәя.

6.00 Бу сәгатьтә канга шикәр белән аминокислоталар күп эләгә. Димәк, организмны көндәлек энергия ихтыяҗын тулыландырырга, ягъни җир җимертеп эшли башларга бар да әзер, дигән сүз. Бу вакытта эшләү һәм уку күбрәк нәтиҗә бирә.

10.00 Бу – кан әйләнеше актив вакыт. Баш мие кан белән яхшы тәэмин ителә. Бу сәгатьтә ишеткән, күргән, укыган әйбәтрәк истә кала. Хәтта иң катлаулы мәсьәләләр дә чишелә.

11.00 Бу вакытта йөрәк ешрак тибә. Организм күбрәк түземлек күрсәтә. Әлеге сәгатьтә без стресска яхшырак каршы торабыз.

12.00 Ашказанында кислоталар күләме арта. Димәк, ашарга вакыт. Бер үк вакытта ашказанына да ял кирәк. Ятып ял итеп алу да яхшы булыр.

14.00 Бу сәгатьтә хәтерләү сәләте кабат яхшыра. Авыруны да бик сизмисең. Шуңа күрә, мәсәлән, теш табибына бару өчен бик кулай вакыт.

16.00 Бу вакытта кан әйләнеше һәм кан басымы икенче мәртәбә җанлана. Спорт белән шөгыльләнүчеләр яхшы нәтиҗәгә ирешергә мөмкин.

17.00 Бу вакытта ашап алсаң, яхшы.

18.00 Сулыш алу ешая һәм мөмкин кадәр күбрәк саф һава сулау мөһим. Йөреп керү һәм мөһим мәсьәләләр чишү сәгате бу.

19.00 Пульс әкренәя, кан басымы төшә. Баш мие эшчәнлеге дә бик актив түгел. Зиһенне туплау кыенлаша.

21.00 Бу вакыттан соң ашарга ярамый: ашказаны икенче көнгә кадәр азыкны эшкәртергә өлгерми. Баш миенең эшчәнлеге нык кими.

0.00 Стресс гормоннары бөтенләй бүленеп чыкмый диярлек. Бу – көн дәвамында алган стресслы тойгыларны «эшкәртәэшкәртә» йоклау өчен менә дигән вакыт.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

КЫРЫКМАСА-КЫРЫК МӘШӘКАТЬ

Белеп тор!

Кәтлит-пилмәнле чор

Студентларның яңа уку елы башланды. Шәһәргә килеп укучы егет-кызлар «кәтлит-пилмәннәр диетасы»на утырды дигән сүз бу. Хәер, яшьләр генә түгел, үзебезнең арада да «ярымфабрикат»ларга мөкиббән китүчеләр байтак. Шулай икән, мондый ризыкларны ничегрәк сайларга?

Беренче чиратта продукциянең җирле җитештерүчеләрнеке булуы яхшы. Товар сыйфатын кемгә караганда да ныграк кайгыртса алар чөнки. Икенчедән, составын иренмичә укып чыгарга кирәк. Башта ризыкка иң күп күләмдә кертелгән продуктлар күрсәтелә. Иң аз кертелгәне ахырга кала. Мәсәлән, беренче сыер ите дип язылган икән, димәк, кәтлит составында иң күп күләмдә алынган ингредиент шул. Аннан инде башка төрле итләр күрсәтелергә мөмкин. Иң дөрес состав бу. Ә менә үсемлек аксымы дип күрсәтелсә, саграк булыгыз: монысы соя дигәнне аңлата. Кәтлитне кыздырганнан соң бик яхшы күренә ул: иттән ясалган кәтлит бераз кечерәеп калса, ә үсемлек аксымыннан ясалганы, киресенчә, күпереп, зураеп китә. Мондый ризык арзан тора, киштәгә ташламалы товар буларак куела. Соялы кәтлиткә әле тагын крахмал, сөяк оны, иттарткычтан чыгарылган кимерчәк тә өстәлә. Әйбәт кәтлит иттән, он, тоз һәм тәмләткечләрдән генә торырга тиеш.

Тәмләткечләргә килсәк, һәркайсы аерым күрсәтелергә тиеш. Әйтик, сарымсак, кара борыч, паприка дип. Ә инде бер сүз белән генә, «специи» дип язылган икән, димәк, организм өчен зарарлы өстәмәләр – ис-тәм керткечләр, кыскасы, «химия» өстәлгән дигән сүз.

Ярымфабрикатлар, җебегәннән соң, тагын катырып куелган булырга мөмкин. Шуңа күрә камыры ярылып киткән пилмән алмагыз. Бу шулай ук эремчек пилмәненә дә кагыла. Камырның төсенә дә игътибар итегез. Никадәр сарырак булса, шуның кадәр яхшырак. Табигый йомырка сарысы күп кулланылганын аңлата бу. Аннан килеп, «кулдан ясалган пилмән» дигән сүзләргә дә егылып китмәгез. Аларның барысы да бер төсле икән, димәк, иseме җисеменә туры килми. Әлбәттә инде, мондый пилмәнне кыйммәт бәядән алуның хаҗәте юк.

vk.com

Бакчачы почмагы

Көз җиту белән бакчачыларның мәшәкате кимеми. Көн туды исә, сораулар артып кына тора. Укучыларыбызны борчыган сорауларга бакчачы Эльмира ИСХАКОВА белән җавап эзләдек.

:: Бакчама алмагач һәм груша утыртырга йөрим. Дөрес итеп утырту серләрен аңлатып үтсәгез иде.

– Алмагач, груша кебек орлык төшле җимеш агачларын утырту өчен чокырның зурлыгы 80х60 см тирәсе булырга тиеш. Ә менә абрикос, чия, кара чия һәм сөяк төшле башка җимеш агачларын 60х40 см чамасы үлчәмдәге чокыр казып утыртырга кирәк. Казыганда, туфракның өске һәм аскы катламнарын бер күчкә түгел, ә аерым-аерым салыгыз. Ник дигәндә, утыртканда, өске катламны аска салырга кирәк булачак. Аскы катлам өстә кала. Чокыр төбенә салынырга тиешле өске катлам туфракны черемә һәм көл белән катнаштырырга кирәк. Орлык төшле агачларга – 3 чиләк черемә һәм 1 кг көл, сөяк төшлеләренә 2 чиләк черемә һәм 0,5 кг көл кирәк булачак. Черемә һәм көл таба алмыйсыз икән, орлык төшле агачлар туфрагын – 1 кг суперфосфат яки 0,5 кг двойной суперфосфат һәм 130 г күкертле калий белән, ә сөяк төшлеләренекен 800 г суперфосфат яки 350 г двойной суперфосфат һәм 90 г күкертле калий белән катнаштырыгыз. Ашламалы туфракны аска салыгыз. Су сибегез. Өстенә ашламасыз туфрак салыгыз да агачны урнаштырыгыз. Тамырлары ашламалы туфракка тиеп тормасын, юкса алар «яначак». Аннан килеп, тамыр муенсасын (тамырларның башланган өлеше) дөрес калдырырга кирәк. Чия, кара чиянеке – туфрак белән 1–2 см тирәсе күмелергә, алма, груша, слива, абрикос, алычаныкы җир белән тигез калдырылырга тиеш. Бу агачларның тамырлары балчыгын кул белән бераз сыпырып караганда да күренсен. Ләкин аны прививка (анысы өстәрәк калдырыла) белән бутарга ярамый. Тамыр муенсасы дөрес калдырылмаган очракта, агач начар яшәрә. Көздән утыртканда, азотлы ашлама кулланырга ярамавын да онытмагыз.

Кышын өшемәсен өчен, төбенә 20 см биеклектә черемә яки салам салып калдырырга кирәк. Яшь агачларны рәттән ике ел төрегез. Кар яуган саен, төбенә кар өегез.

:: Гладиолус суганчаларын кайчан казып алырга?

– Әле һаман чәчәк атып утырсалар, кызганып тормыйча, кисеп алыгыз. Суганнары кыш чыгарга тулысынча әзер булсын өчен чәчкәләрен кискәннән соң бер ай вакыт кирәк чөнки. Юкса, көннәр салкынаеп китсә, соңга калуыгыз бар. Кыскасы, чәчәкләрен кискәннән соң суганчаларын бер айдан соң казып алу дөрес булачак.

:: Агач-куакларның кирәкмәгән ботакларын кисәргә вакыт җитмәдеме икән инде?

– Әлеге эшкә тотынырга иртәрәк әле. Гадәттә яфраклар коелгач кына башкарыла әлеге эш. Бу чорда агачларның суты акрынрак йөри башлый, агач стресска азрак бирешә. Ботаклар кисүне суыклар башланырга 2–3 атна кала, сентябрь ахыры – октябрь башына планлаштырып куярга кирәк. Суыкларга кадәр аңа ныгып калу шарт. Соңга калынса, ботакның киселгән өлеше өшергә һәм агач корырга мөмкин.

:: Җимеш агачлары-куәсәләрен чистарту тәртибе турында аңлатып үтсәгез иде.

– Бу эшне менә хәзер, корткычларга каршы препаратлар сиптергәнче, яфраклар әкренләп коела башлаган бер мәлдә башкарып куярга кирәк. Карт агачларны тимер щетка белән иске кайрысыннан чистартабыз. Ләкин өсте куба торган катламыннан гына арындырабыз. Ни өчен чистартырга? Беренчедән, кышка кайры астына корткычлар кереп кача һәм шунда күкәй сала. Икенчедән, агач чери башларга, өченчедән, мүк басарга мөмкин. Иске кайрысыннан арындырганнан соң агач җиңелрәк сулый башлый. Уңышы да яхшыра. Чистартканнан соң, шул урыннарны тимер купоросы эремәсе (10 литр суга 100 грамм тимер купоросы кушарга) белән эшкәртәбез. Яралары булса, сылыйбыз. Агач кәүсәсендә куыш барлыкка килсә, башта бик әйбәтләп чистартып, әчен шул ук тимер купоросы эремәсе белән эшкәртәбез һәм цемент эремәсе тутырып куябыз. Октябрь ахырында кәүсәләренең аскы өлешен агартабыз. Кышка махсус буяу белән агарту яхшырак. Чистартканнан соң чүбен яндырабыз яки чүплеккә ташлыйбыз.

:: Язын виноград үсентесе утырткан идем. Әйбәт кенә үсеп китте. Аны кышка ничек әзерләп калдырырга икән?

– Иң элек әйбәтләп су сибәргә кирәк. Су туфракның өске катламына тулысынча үтсен. Якынлашып килүче кыраулларга бирешмәүгә ярдәм итә ул. Су сипкәннән соң берничә көн узгач, туфрагын йомшартып алыгыз. Компост яки тирескә бераз кош тизәге өстәп ашлагыз. Сыек ашлама да ясарга мөмкин. Моның өчен кош тизәгенә җылы су салып (1:3 нисбәтеннән), 9 тәүлек тотыгыз. Шуннан әлеге катнашмага 1:8 нисбәтеннән җылы су кушып, төбенә сибегез. Бер виноград куагына якынча 0,4 литр сыек ашлама кирәк. Ә инде агач яфраклары коелып беткәч, яшь үсентенең яфракларын өзеп ташлагыз һәм кисмичә генә ботакларын бәйләгән урыныннан җиргә төшереп, чыршы ботаклары белән каплап куегыз. Әйе, ботакларны беренче елында киселми.

:: Беренче кыраулларга кадәр чәчәк атып утырсын өчен петунияләрне нишләтергә?

– Ашлап җибәрсәң, кара көзгә кадәр шау чәчәктә утырачаклар! Ашламаны болай ясарга мөмкин. Кечерәк чиләккә 1 литр җылы су салып, 100 грамм чүпрә һәм 3 аш кашыгы шикәр комы өстибез. 2 көн салкынча урында тотабыз – чүпрә кабара. 10 литр суга 2 стакан күләмендә шушы катнашманы өстәп болгатабыз һәм үсемлекләр төбенә сибәбез.

РОЗА ГАЛИЕВАДАН КӨЗГЕ БӘЛЕШ

Тәмле булсын!

Кирәк: 200 грамм катырылган кызыл карлыган (карасы булса да ярый), 200 грамм физалис, 200 грамм миләш, 150 грамм он, 1 чәй кашыгы камыр күперткеч (разрыхлитель), 2 аш кашыгы крахмал, 100 грамм атланмай, 150 грамм шикәр комы, 2 йомырка, 2 чәй кашыгы шикәр пудрасы, пычак очында ванилин.

Көзге җиләкләрне әйбәтләп юабыз. Кәгазь сөлгегә бушатып кипшертәбез. Йомшара төшкән атланмайга ванилин һәм 2 аш кашыгы шикәр комы өстәп, барысы бергә кушылып беткәнче, кул белән ышкыйбыз. Шуңа 1 йомырка сытып болгатабыз. Онга камыр күперткеч, крахмал, майлы катнашманы өстәп, камыр басабыз. Камырны җәеп, майлы табага урнаштырабыз. Өстенә җиләкләрне тезәбез. Йомырканы күпертеп, бәлеш өстен шуның белән майлыйбыз һәм 180 градуска кадәр җылытылган мичкә 25 минутка куябыз. Әзер булгач, өстенә шикәр пудрасы сибәбез.

Матур бул!

Ташкабактан – шәп битлек

Бу яшелчәдән майлы тирене сафландырып, шомартып җибәрә торган бик әйбәт битлек ясарга мөмкин.

Өлгереп җиткән бер кисәк ташкабакны блендерда изегез. Алоэ яфрагын тышчасы һәм энәләреннән арындырыгыз. Йомшагын изеп, ташкабакка кушыгыз. Килеп чыккан катнашманы биткә сылап, 10–15 минут тотыгыз. Салкын су белән юып төшерегез. Бит тиресе тартылыбрак киткән кебек булса, крем сөртегез.

КӨН ДӘ БЕР СОРАУ

Кайчагында көндәлектәге мәсьәләләргә дә дин күзлегеннән карау зыян итмәс. Сәхифәбезне бу юлы укучыларыбызны борчыган сорауларга җавап эзләүгә багышладык.

Сорауларга Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ җавап бирде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

?Чит илгә күченеп китәргә җыенам. Исемемне үзгәртергә телим. Татар исемен интернациональ исемгә алмаштырсам, гөнаһ булмыймы?

ГӨЛЧӘЧӘК

– Исем Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Кыямәт көнендә сез әтиегезнең һәм үзегезнең исемегез белән чакырылырсыз», – ди. Шуңа да балаларга һәрвакыт хәерле исемнәр бирергә кирәк. Бу – ата-ананың бурычы. Әгәр сезнең исемегез яхшы мәгънәдә икән, бу – ата-ананың сезнең һәм Аллаһы Тәгалә каршында үтәлгән бурычы. Шул исем калса хәерлерәк тә. Иң мөһиме – кешенең яхшы булуы, ә исем – исем инде ул. Кешенең калебе изге гамәлләргә тартым булырга тиеш.

?Бурыч-әҗәтләрем күп. Аннан котылу чарасы юкмы?

Исемем редакция өчен генә

– Дога кылырга. Махсус догасы бар. Бурыч – җаваплы нәрсә. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кеше бик зур әҗер-саваплар белән килсә дә, бурычы калса, оҗмахка кермәс», – ди. Намаз укыганда, Аллаһы Тәгаләдән сорагыз. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кем дә кем үзенә фәкыйрьлек килмәвен теләсә, ашаганчы һәм ашаганнан соң кулларын юсын, иртәнге якта зикер әйтсен», – ди. Иң нәтиҗәле ысул бу.

?Намаз укымаган, дога кылмаган кешенең уразасы, барлык шартларын үтәсә, тыелганнардан тыелса да, кабул булмый, дигәнне ишеткәнем бар. Бу чынлап та шулаймы?

Рамил СӘЙФИЕВ

– Ураза ул – ислам динендәге баганаларның берсе. Кеше намаз укымый, ураза тота икән, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, ул кабул булыр. Аллаһы Тәгалә рәхимле, киң кодрәтле ул. Әмма гыйбадәтләрнең барысын да башкарсак хәерлерәк. Догасын да, намазын да укыйк, уразасын да тотыйк.

?Шәһәрдә никах мәҗлесе оештырырга телибез. Ресторанга мулла чакырып, соңрак тамада белән бәйрәм ясау иде исәп. Барысы да хәләл шартларга туры киләчәк. Соравым шул: никах укыган өчен дин әһеленә ничә сум бирергә икән? Аның билгеле бер күләме бармы?

АЙГӨЛ. Казан

– Ашларда, мәҗлесләрдә күпме акча бирергә, дигән сорауга алдагы сәхифәләрдә бер җавап биргән идек инде. Безнең җирлектәге гореф-гадәт бу. Әгәр дә кешенең мөмкинлеге бар икән, акча бирә. Имам, хәзрәт үз эшен башкара бит. Дини йолаларны үткәрү аның төп вазыйфасы санала.

?Мөселман гаиләсенә башка диндәге баланы кызлыкка-уллыкка алырга ярыймы?

ГАЛИЯ

– Әлбәттә, ярый. Тәрбиягә алу рөхсәт ителә. Бу баланың диненә, милләтенә карамаска да була. Әмма аны яхшы кеше итеп тәрбияләү, яхшы шартларда үстерү мөһим. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дистәгә якын баланы тәрбиягә алып үстергән. Бу – җаваплы һәм саваплы эш.

?Тәнгә дини сүзле татуировка ясатырга телим. Бу гөнаһ саналамы?

Равил САФИН

– Аллаһы Тәгалә тәнебезне камил кылды. Без исә аңа рәсемнәр төшереп, үзгәрешләр кертергә тиеш түгел. Бу дин буенча тыелган. Әгәр дә кеше Аллаһ, Коръән яисә Пәйгамбәребез (с.г.в) сүзен тәненә төшертеп, шушы тән белән мунчага, бәдрәф ише җирләргә керә икән, бу өстәмә гөнаһ булып та языла әле. Дини генә түгел, башка төр татуировка да ясалмаска тиеш.

?Кешегә сихер, бозым ясалганын ничек аңларга мөмкин икән?

Исемемне күрсәтмәвегезне сорыйм

– Билгеләре күп аның. Аларны санаганчы, сихер-бозымга дучар булмау юларын әйтсәк, хәерлерәктер. Иң элек бу – госелтәһарәтле булу. «Фатиха», «Аятел Көрси», «Әл Кәфирүн», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләрен уку, үзеңне өшкерү. Аннан, башкалада махсус мәчетләр дә бар бит. Аларга мөрәҗәгать итәргә була. Бисмилла әйтеп ашап, Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп һәм тыелып яшәсәк, кешегә сихер-бозым кермәс.

?30 яшемә җитәм, әле өйләнмәгән. Барысы да: «Кайчан өйләнәсең?» – дип кызыксына. Дин буенча ир-атның өйләнергә тиешле берәр вакыты бармы?

АЙДАР. Казан

– Өйләнү, кияүгә чыгу – һәр кешенең бурычы. Пәйгамбәребез (с.г.в) да: «Өйләнүдә бар бәрәкәт, нигъмәтләр», – ди. Кеше ниндидер сәбәпләр буенча өйләнмәгән икән, вакыты җиткәч, өйләнер. Чит кеше исә мондый сораулар белән аптыратырга тиеш түгел. Бу – әдәпсезлек.

?Туган көнгә дога сүзләре төшерелгән матур картина бүләк иттеләр. Аны йортның кайсы җиренә урнаштырсак, хәерлерәк булыр?

Диләрә ИСХАКОВА

– Шамаилне иң түргә элеп куйсагыз, бик хәерле булыр. Анда изге сүзләр язылган бит. Алар кадерсез җирдә булырга тиеш түгел.

«Йөрәкләрегез үле бит!»

Гыйбрәт ал

Ибраһим ибн Әдһәм Басра шәһәренең урамнарыннан барган вакытта, Басрада яшәүче кешеләр җыелып, хәзрәттән:

– Әй, хәзрәт, Аллаһы Тәгалә үзенең китабында: «Сез Миннән сорагыз, Мин догаларыгызга җавап кайтарырмын», – дип әйткән. Ни булды икән безгә? Без Аллаһы Тәгаләдән сорыйбыз, әмма ул безгә җавап бирми. Нигә догаларыбыз кабул булмый икән? – дип сораганнар.

Ибраһим ибн Әдһәм исә:

– Ничек Аллаһы Тәгалә догаларыгызга җавап бирсен? Сезнең күңелләрегез, йөрәкләрегез үле бит. Күңелләрегезнең, йөрәкләрегезнең үлүендә ун төрле сәбәп бар. Беренчесе, без Аллаһы Тәгаләгә иман китердек, Аны таныдык, дип әйтәсез. Коръәнне бик матур итеп укыйсыз, әмма Коръән өйрәткәнчә эшләмисез. Аллаһының илчесе Мөхәммәтне (с.г.в.) сөябез, хөрмәт итәбез, дип әйтәсез, әмма ул күрсәткән юлдан бармыйсыз. Шайтан – безнең дошманыбыз, дип сөйлисез, әмма эшләгән эшләрегезгә карасаң, аны үзегезгә дус күрәсез. Җәннәткә керергә телибез, дисез, әмма анда эләгер өчен бернинди тырышлык куймыйсыз. Җәһәннәм утыннан котылырга кирәк, дип кычкырасыз, әмма үзегез анда илтә торган юллардан йөрисез. Үлем тиздән килер, безне алып китәр, дип сөйләргә буласыз, әмма ул үлемгә бер дә әзерләнмисез. Кешеләрне тикшереп, гомерегезне уздырасыз, әмма үзегезнең кимчелекләр чокырына төшеп батканыгызны сизмисез дә. Сезнең арагызда үлгән кешеләрне, кабергә илтеп, күмеп куясыз, әмма шуннан гыйбрәт ала белмисез. Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләрен иртә, кич ашап торасыз, бар өстенә «юк» дисез, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтә белмисез. Әй, Басрада яшәүче кешеләр, сез бит тере булып күренсәгез дә, Аллаһы Тәгалә каршысында мәетләр кебек яшисез. Мәетләр Аллаһы Тәгаләдән нәрсә сорый алсыннар? Берәр әйбер сорасалар да, Аллаһы Тәгалә мәетләргә ничек җавап бирсен?! Догагызның кабул булуын теләсәгез, күңелләрегезне терелтеп, мәет булудан үзегезне коткарыгыз, – дип җавап кайтарган.

Йәгез, бер дога!

АШ ДОГАСЫ

Һичшиксез, «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим» дип башларга һәм ошбу доганы укырга кирәк: «Әллаһүммә бәәрик ләнәә фииһи вә әтгыймнәә хәйран минһү. Әллаһүммә әгътыйнәә ризкан хәләәлән вә әнтә хайрур-раазикыйин. Әллаһүммә нәввир кулүүбәнәә вәрхәмнәә вәрьда ганнәә. Вә әгътыйнәә тәмәәмә нигъмәтикә вә дәвәәмә нигъмәтикә вә тәмәәмә тәүфиикыйкә».

Мәгънәсе: «Әй, Аллаһым! Ашларыбызга бәрәкәт бир, болардан да хәерлерәк ашларны ашарга насыйп кыл. Безгә хәләл ризык бир. Чөнки Син – ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе. Аллаһым! Күңелләребезне яктырт, безгә мәрхәмәт ит һәм бездән разый бул. Безгә нигъмәтеңнең дәвамын һәм тәмамын әйлә, йә Рабби!»

Өч хәдис

«Кешегә сабырлыктан да яхшырак һәм киңрәк берни дә бирелмәгән».
«Бар вәгазь кешенеке, үлем – Аллаһның вәгазе».
«Алдакчыга әйләнер өчен, кешенең ишеткән барлык сүзләрен калганнарга сөйләп баруы да җитә».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Газетабызның узган санда чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Кукмарадан ***Илзия Харисова*** *танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Гүзәл Уразова репертуарыннан «Ромашкалар», Иркә башкаруындагы «Тормыш җилләре» һәм Зөлфия Минһаҗеваның «Миләшкәем» җырларын яшергән идек.*

Әлеге җыр елак күзләрдә аеруча актуаль. Җырчының күңелен сагыш баскан, шуны аңларга куша ул.

Бу җыр да көз турында. Искән җилләрнең газапларны алып китүен, ә кешеләрнең сагышларга бирелмәвен тели җырчы.

Җырны башкаручылар, киресенчә, яңгырларның явуын тели. Янган йөрәкне шул басар, зарларны шул юар, ди алар.

БАЙ ХӘЙРУЛЛИН:

«КИНОНЫ ҮСТЕРҮ ДӘҮЛӘТ БУРЫЧЫ ГЫНА ТҮГЕЛ»

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенең кунагы – режиссер һәм видеограф, «Биләр. Мирас хәзинәсе» фильмының авторы Бай ХӘЙРУЛЛИН. Үз акчаңа сыйфатлы фильм төшерү авырмы? Тарихи фильмнарны яшьләр өчен дә кызыклы итеп ничек төшерергә? Яшь, өметле кинематографистан тагын нинди проектлар көтәргә? Без әнә шулар хакында сөйләштек.

:: Ни хәл?

– Хәлләр әйбәт, Аллага шөкер. Күптән түгел генә мөселман кинофестивале узып китте. Аның кысасында миңа «Биләр. Мирас хәзинәсе» фильмын күрсәтергә насыйп булды. Гомумән, фестиваль минем өчен үзенчә бер бәйрәм һәм тәҗрибә туплау өчен яхшы мөмкинлек булды. Хәзерге вакытта Иске Казан турында фәнни-популяр фильм төшерәм.

:: Балачагың турында сөйлә әле.

Көненә 2500 калория булырга тиеш. Күп итеп су эчәргә кирәк. Күзәнәкләр сыеклык белән тулыланганда, балалар сирәк авырый. Иртә белән балага бер йомырка, ботка, сыр бирү дә җитә. Аксымы да, углеводы да булачак. Какао, сөтле кофе бирергә мөмкин. Тик какаоны пешерергә кирәк. Төшке аш һәрвакыт кайнар булсын. Яшелчә белән ит ашау яхшы. Итне бер тәүлеккә 100 грамм ашарга кирәк. Яшелчә, җиләк-җимеше дә булсын. Әти-әниләр балаларының канын – ярты ел саен, шикәрен өч айга бер тапкыр тикшертеп торсын, чөнки уку процессында балалар стресс кичерә. Д витамины, көн саен иртән йодомарин бирегез.

Илгиз ХӘЙРУЛЛИН, Әтнә районының «Ленин» кооперативы җитәкчесе:

– Элек мәктәпләргә үзебез суйган итне, сөтне бик теләп бирә идек, хәзер аларга башка җирдән алырга ярамый. Товарны тендер откан компанияләр генә китерә. Мәктәп бакчасында үстергән помидорын, алмасын да консервлап ашатырга рөхсәт юк. Бу бит – башка сыймаслык әйбер. Мәктәп бакчасына кергән идем, исем-акылым китте. Алмалар өлгергән, җыймыйлар. Сатып алучы таба алмыйбыз, диләр. Элек алманы киптерә, аннан компот яба, яшелчәләрдән консервлар ясыйлар иде. Хәзер үстергән әйберне каядыр сатарга мәҗбүрләр. Менә шундый хикмәт.

АЕРЫЛМАГЫЗ!

Росстат мәгълүматларына ышансаң, Россиядә аерылышучылар саны арткан. Ел башыннан июль аена кадәр 318 мең пар рәсми төстә мөнәсәбәтләренә нокта куйган. 2021 елның шушы ук чорындагы күрсәткеч белән чагыштырганда, 3,3 процентка күбрәк сан бу. Гаҗәпкә калдыра торган тагын бер мәгълүмат: мөнәсәбәтләренә нокта куючылар буенча алдынгылыкта Төньяк Кавказ төбәге тора. Сөендергәне исә – Татарстандагы үзгә вазгыять. Республикада никахлашучылар саны аерылышучыларга караганда күбрәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авырткан урын

Росстатның тагын бер санлы мәгълүматына күз салыйк. Соңгы 10 елда Россиядә гаилә коручылар саны кими. Әйтик, 2011 елда гомер юлын бергә узарга 1316011 пар килешкән булса, 2021 елда андыйлар саны 923550 генә булган. Гаилә корырга 2020 елда да ашыкмаганнар. Коронавирус пандемиясе котырган чорда никахлашучылар саны 770857 булган. Аның каравы аерылышу статистикасы үзгәрешсез диярлек: Россиядә ел саен 600 меңләп гаилә таркала.

Татарстан Хөкүмәте дәрәҗәсендә аерылышуга бәйле вазгыять еш телгә алына. Гаилә таркалуга юл куймас өчен, чараларны катгыйландыру буенча тәкъдимнәр дә ишетелә. Мәсәлән, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ЗАГС идарәләрендә һәм судларда аерылышу процессын катлауландыру кирәк дигән фикердә. 2016 елда Дәүләт Советы Россия Дәүләт Думасына закон проекты белән дә чыгып карады. Депутатлар аерылышу срогын 3 айга кадәр озайтырга, гаиләдә балигълык яшенә җитмәгән бала булган очракта, парларның берсе аерылышуга риза түгел икән, гаиләне «дуслаштырырга» кирәк дигән тәкъдимнәрен җиткерде. Әмма федераль дәрәҗәдә алар хуплау тапмады.

Росстатның мөнәсәбәтләргә бәйле быелгы саннары әллә ни сагайтмый анысы. 7 ай эчендә 12810 пар рәсми төстә гаилә булып яши башлаган. Аерылышулар саны – 8654. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, гаилә коручылар саны үзгәрешсез калган, үсеш 0,1 процент кына. Ә аерылышучылар саны 5,5 процентка кимегән.

Шулай итеп республика гаилә коручылар саны буенча Идел буе федераль округындагы төбәкләр арасында беренчелектә тора. Мари Иле белән чагыштырып карасак, бездә хәлләр чынлап та алай ук мөшкел түгел дияргә мөмкиндер. Күршеләрдә 7 ай эчендә нибары 1535 пар никахлашкан.

Яратканга ябышкан, ошамагач – аерылышкан

Татарстанның ЗАГС идарәсе җитәкчесе урынбасары Ренат Әхмәтҗанов сүзләренчә, яңа гаилә корганнар өчен иң авыр чор – уртак тормышның беренче биш-ун елы. Сүз уңаеннан, 2021 елдагы аерылышуларның 60 проценты шундыйлар өлешенә тигән.

Араларны ничек ялгап буласын ЗАГС та белми. Ренат Әхмәтҗанов әйтүенчә, бу җәһәттән идарәнең мөмкинлекләре чикле. «Былтыр никахлашучыларның 79 проценты суд карары нигезендә аерылышты. Кайбер җирлекләрдә бу күрсәткеч 100 процентка җитә. Еш кына аерылышу турында карарны суд ир йә хатыннан башка гына да кабул итә. Арча, Мөслим, Баулы районнарында, мәсәлән, гаиләләрнең яртысыннан артыгы шул рәвешле таркалган», – дип аңлата ул. Аерылышучыларның иң күп өлеше 30–39 яшь төркеменә карый икән.

Татарстан Югары суды рәисе урынбасары Айдар Галиәкбәров әйтүенчә, гаилә таркалудан бу процессны катлауландыру саклап калыр иде. Белгеч фикеренчә, аерылышканда медиатор (бәхәсне чишәргә ярдәм итүче өченче нейтраль, бәйсез зат, арадашчы. – **Авт.**) ярдәменнән файдалану законда ук язылырга тиеш. Мондый ярдәмченең иргә дә, хатынга да аерым булуы мөһим.

– Советлар чорында аерылышучыларга уйлар өчен алты айга кадәр вакыт бирелә иде. Хәзер өч кенә. Аерылышу процессы халык утырышчысы катнашында уза иде. Бу – гадәттә, мөнәсәбәтләренә нокта куярга җыенучыларның эш урыныннан вәкил. Алар бу кешеләрне белә, проблемалары белән дә таныш. Хәтерлим, халык утырышчысы булган кешеләр парны татулашырга өнди иде. Алар хәзер дә кирәк, – дип саный Айдар Галиәкбәров.

Гражданнар эшләре буенча юрист Ләйсән Мортазинаның да фикере суд вәкиленең фикере белән охшаш. Ул да, медиаторларны җәлеп итү нәтиҗә бирер иде, дип саный.

– Аерылышучыларның санын киметү өчен медиатор ысулын кулланырга кирәк. Әйтик, читтән юрист яллау. Судка кадәр психолог, юрист белән эшләү дә файдалы булыр иде, алар парларга бергә калуның кулайрак булуын аңлатыр иде, – ди ул. – Әгәр дә инде кешеләр аерылышуга барып җиткән икән, һич югы моның уңайсыз, тискәре, алар белмәгән якларын аңлатырга кирәк.

Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Әсәдуллинаның аерылышуга карата үз фикере. Гаилә коручысы булмагач, аерылышучысы да калмас, дип борчыла ул. Белгеч сүзләрендә хаклык бар: яшьләр гаилә корып, бергә яшәргә ашыкмый.

– Гаилә кору түгел, бала алып кайту турында әйтмибез дә. Күпләр 35 яшькә кадәр бу хакта уйларга да теләми. Юкса репродуктив яшьнең чиксез түгеллеген аңлыйлар да инде, – ди урынбасар. – Минемчә, белем бирү үзәкләрендә гаилә белеме курсы кертелергә тиеш. Әмма ул балалар өчен кызыклы формада булсын иде. Ул көллият, вузларда укытылса яхшы. Аннан, мәктәпләрдә җенси тәрбия дәресе бөтенләй юк. Балаларга бу хакта дөрес һәм төгәл итеп аңлатучы ресурс, белгечләр, программалар да юк.

Белгечләр ни уйлый?

Өйләнгәндә җырлап, өйләнгәч, еламас өчен нишләргә? Аерылышуның төп сәбәпләре нинди? Психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗановадан шулар турында сораштык.

– Соңгы арада парлар, гаиләләр белән еш очрашырга, алар белән эшләргә туры килә. Шуңа күрә дә бу мөнәсәбәтләргә бәйле сораулар миңа якын, эчке «кухня»сын беләм, – ди белгеч.

Психолог сүзләренә караганда, аерылышу дигән бәла гаиләдәге мөнәсәбәтләр тибының үзгәреше белән тыгыз бәйләнгән. «Кайчандыр гаилә дигән төшенчәнең традицион аңлатмасы бар иде. Аның үз кагыйдәләре, традицияләре булды. Дөнья үзгәргәч, ул да, гаилә мөнәсәбәтләре дә үзгәрми калмый, билгеле», – дип саный Чулпан Нигъмәтҗанова.

Гаиләләр нинди сәбәпләр аркасында таркала соң? Психолог әйтүенчә, беренче урында хатын-кызның икътисади мөстәкыйльлеге һәм социаль тигезлегенең көчәюе тора. «Хәзерге вакытта хатын-кыз үз өстенә бик күпне ала. Җаваплылык аның өстендә, ул барысын да булдыра ала. Шул рәвешле ир-атның «мин-минлеге», ягъни эгосы кими», – дип аңлата ул.

Икенче сәбәп исә сыйнфый, милли, дини кагыйдәләрдән – азат булу. «Хәзер алар артык көчле түгел. Элегрәк гаиләдә бу кагыйдәләр беренче урында тора иде», – ди белгеч.

Өченче сәбәп – аерылышучыларга булган караш. «Хәзер аерылышуга тискәре мөнәсәбәт юк диярлек. Негатив караш кимеде. Киресенчә, җәмгыятькә «Аерылышкач рәхәт, ирек тоясың, канатлар үскәндәй була» дигән мәгълүмат җиткерелә. Калыплашкан фикерләү юк, кыскасы», – ди Чулпан Нигъмәтҗанова.

Гаиләләр белән эшләгәндә, психолог үзе өчен аерылышуга китерә торган яңа сәбәпләрне дә ачыклаган.

– Сайлаган ярыңа карата зур таләпләр кую һәм аларның чынбарлыкка туры килмәве шулай ук – аерылышуга илтә торган бер сәбәп. Мин февраль аенда өйләнешеп, яши башлаган бер гаилә белән эш итәм. Алар очрашып йөргән мәлдә бер-берләре өчен камил, идеал булырга шулкадәр тырышканнар. Гаилә корып, бергә яши башлагач, егет белән кыз булып йөргән чактагы битлекләр салынган. Алар – икесе дә ике төрле кеше, бер-берләренә бөтенләй туры килмиләр икән ләбаса, – дип сөйләде Чулпан Нигъмәтҗанова. – Тагын бер сәбәп – җенси яктан бер-береңне канәгатьләндермәү. Бу хәзер аеруча актуаль. Бу – аерылышуга да, хыянәткә дә илтә торган сәбәп. Матди яктан канәгать булмау да араларны салкынайта. Аннан, уй-фикер, борчуларны, теләкләрне уртага салып сөйләшү дә юк. Менә шул да аңлашылмаучанлыкка китерә. Югыйсә гаилә нигезендә аралашу да булырга тиеш. Мин генә бар, мине генә аңларга тиешләр, дип булмый. Кешеләр киләчәкне күрүче дә, экстрасенс та түгел бит.

Чулпан Нигъмәтҗанова әйтүенчә, Татарстанда аерылышучыларның аз булуының да үз сәбәпләре бар.

– Татарстан – гаилә кыйммәтләре һәм традицияләре үзәге ул. Алар безнең нигезне тәшкил итә, бу кыйммәтләр буыннан-буынга күчеп бара, – дип аңлата белгеч. – Гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру, гаилә абруен күтәрү буенча эш алып барыла, чаралар оештырыла. Бу да үз җимешен бирми калмыйдыр. Шуны да әйтә алам: хәзерге яшьләр бик акыллы, белемле. Алар гаилә корган очракта да, гаилә эчендә берәр сорау, низаг туа калса, аның асылын аңларга, сәбәпләрен ачыкларга тырыша. Әйткәнемчә, психолог буларак андыйлар белән күп эшләргә туры килә. Төрле алымнар белән гаиләләрне саклап калуга ирешкәнем бар. Тагын бер сәбәп: Татарстанда дини кыйммәтләргә таянып яшәүче мөселманнар күп. Бу гаилә корганда да зур роль уйный.

Чулпан Нигъмәтҗанова әйтүенчә, алдарак санап үткән сәбәпләрдән тыш, иртәме-соңмы мөнәсәбәтләрнең бозылуына китерерлек көчләр дә юк түгел. Иң элек бу кешенең шәхси сыйфатларына бәйле икән. «Эгоизм бу очракта бик зур роль уйный. Андыйларга үз-үзләренә «Миңа минем хаклы булуыммы, әллә мөнәсәбәтләрне саклап калуым мөһимрәкме?» дигән сорауны бирергә киңәш итәр идем. Чираттагы фактор – психологик җәрәхәтләр. Мәсәлән, эти-әниләрнең аерылышуы. Бер-береңә ышанмау, парларның җәмгыятьтә, хезмәт урынындагы дәрәҗәсе, абруе кебек сәбәпләр дә иртәме-соңмы мөнәсәбәтләрнең бозылуына китермәгәе», – ди белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА



Сан

Республикада һәр алтынчы никах – катнаш. Бу елның 7 аенда шундый 2464 гаилә теркәлгән. Ул никахлар санының 19,2 процентын тәшкил итә.

АВЫРУ БАЛА ӘНИСЕ:

«БЕЗНЕҢ ХӘЛНЕ АҢЛАУЧЫ СИРӘК»

«Төенчегем үземнән калмасын дип телим». Азнакайда гомер итүче Алсу Фәрхетдинова әнә шулай ди. 19 ел элек гаиләләренә килгән сынауны баштарак кабул итәргә теләмәсә дә, соңрак язмышына риза була ул. Бәргәләнеп, елап, өзгәләнеп берни эшли алмаячагын аңлый. Бар көчен җыеп, сабыен ничек бар шулай кабул итеп яшәргә өйрәнергә туры килә аңа.

Әбит бәби көткәндә барысы да яхшы була.

– Алиябезне көтеп алдык. Яңа гына тормыш башлаган чак. Табиблар, кызыгыз булачак, дигәч, ничек шатланганымны белсәгез иде! Шулкадәр көттем мин аны, – дип башлады сүзен Алсу. – Әмма сөенеч озакка бармады. Сабыемны бик авыр таптым. Үз хәлем яшәү белән үлем арасында иде. Ә кызымны күрсәтмәделәр. Нидер бардыр дип уйламадым да. Аны реанимациягә алып киттеләр. Ул анда биш көн яткач, мине өйгә язарли башладылар. Бик курыктым. Шуннан соң безне Казанга җибәрделәр. Башкала табиблары да сөендермәде, соңга калгансыз, диләр. Баланың авыру булуы турындагы сүзләрне кабул итә алмадым. Елыйм да елыйм. Ул чактагы халәтемне әйтеп аңлатырлык түгел иде.

Алиядә ДЦПның катлаулы төрен ачыкладылар. Нерв системасына бик нык зыян килгән була.

– Кызыбыз гәүдәсен дә тота алмый, аяк-куллары да тыңламый. Гел ятып торып, тәне бозылмасын өчен, аркасын ярты сәгать саен уып торам. Көненә бер сәгать кенә булса да, Алияне махсус арбада утыртып торырга тырышабыз. Балабыз сөйләшә дә алмый. Бары тик башын селкетеп, «әйе» белән «юк»ны гына сиздерә, – дип сөйли әнисе. – 19 ел буе менә шулай яшибез. Минем Алия туганнан бирле уянмыйча бер сәгать тә йоклаганым юк. Ярты сәгать саен кызымны барып карыйм. Аның инде гел ятып, умырткалыгы да сул якка кәкрәйде. Авыр чаклар күп булса да, бер утырып елыйм да тагын атлап китәм. Кызымны еш кына Казанга алып барырга туры килә. Алия юлны авыр кичерә. Башкала табибларына рәхмәт. Хәлебезне аңлап, машина янына үзләре чыгып карыйлар. Тернәкләндерү үзәкләренә йөртү дә җиңел түгел. Инде хәзер иремнең дә аякларына операция кирәк. Тиздән аны хастаханәгә салалар. Өч ай буе берни эшләргә ярамаячак, диләр. Шуңа да бик борчылабыз. Ә бит ирем бөтен тормышны берүзе алып бара иде. Мин кызым янынннан бер минутка да китә алмыйм.

Алия Фәрхетдиновага ярдәм итәргә теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары:
Алсу Зявдатовна исемендәге Саклык банкы картасы: 2202200951923489.
Тинькофф картасы номеры: 2200700172954165.
Карталар 89061163520 телефон номерына беркетелгән.

Алияне табиблар кат-кат тикшергән. Эчке органнары сау-сәламәт икән. Алсуның инде бер генә теләге бар – сабые үзеннән соң ятлар кулына калмасын иде!

– Мин баламның үземнән башка берәүгә дә кирәкмәсен аңлыйм. Әлегә без аның ничек тә хәлен җиңеләйтергә тырышабыз. Авыру бала үстерү җиңел түгел. Әмма безнең хәлне аңлаучы гына сирәк. Хәтта якыннар да ерагая андый чакта. Берәүгә дә авыру бала тәрбияләргә язмасын. Кызыма көн саен дару биреп торабыз. 3 айга бер тапкыр 18 мең сумлык укол ясатабыз. Төннәр буе сызланып чыкканын күреп, йөрәк сыкрый. Кызымны дәвалау өчен ай саен 50 мең сум чамасы акча кирәк. Әтисе эшләмәгәндә, ничекләр яшәрбез дип борчылам, – ди Алсу. – Әмма кыен чакта Аллаһы Тәгалә ташламый. Юлыбызга яхшы кешеләр чыгарып куя. Көтмәгәндә каяндыр ярдәм килеп төшә. Әнә шуларны уйлыйм да, без ялгыз түгел әле, дөньяда яхшы кешеләр җитәрлек икән дип сөенеп куям. Аларга чиксез рәхмәтләремне укыйм. Караңгы көннәрне яктыртучыларга мең рәхмәт.

ӘТИ НАЗЫ

Буада яшәүче Раушан Зиннәтуллинга өч баласына әти дә, әни дә булырга туры килгән. Хатыны Дамира 40 яшендә бакыйлыкка күчкәч, балаларына ятимлек ачысын сиздермәскә тырышып яши ул.

– Киленебез Наратбаш авылыныкы иде. Улым белән матур яшәделәр. Болай булыр дип кем уйлаган? – ди Назирә апа Зиннәтуллина. – Дамираның вафатына 10 ел инде. Җидесен уздырган көнне кече кызына 3 яшь тулды. Олы балалары аңлый иде инде. Әниләренең хастаханәләргә еш йөргәнен күреп тордылар. Табиблар аның канында яман чир тапты. Бик тә Казан хастаханәсенә алып барасыбыз, терелтәсебез килде. Табибларга күренмәс өчен бик карышты. Ризалашып, хастаханәгә барган көнне үк җан бирде. Күңеле сизенгәндер инде балакаемның.

Дамира өченче бәбиенә узганын башта сиздерми дә. Үзенчә сюрприз ясыйсы килә. Әмма каенанасына серен ача. Төшендә бер кыз бала күрә ул. Сабый Дамирага таба «әни» дип йөгереп килә икән. Чыннан да, озакламый кыз бала дөньяга килә. Әмма әнисез үсәргә насыйп була аңа. Әнә шул сабый барысына да кадерле хәзер.

Назирә апа килененең туганнарына бик рәхмәтле. Алар балаларны бер дә ташламый, гел бергә, ди.

– Киленемнең апа-сеңелләре бик тату. Алар элек тә гел бергә булдылар. Кием алсалар да, кунакка барсалар да, дүртесе йөрделәр. Хәзер дә шул җылылыкны саклыйлар, – ди Назирә апа. – Узган ел кодагыем үлеп китте. Бала хәсрәтләре җиңел түгел шул ул. Кодам ялгыз калды инде хәзер. Күңелләрне юатырга әле дә оныклар бар, дибез.



Әниләре үлгәч, сабыйларны әтиләре Раушан тәрбияли. Олы улы Казанда югары уку йортының 3 нче курсында белем ала, икенче улы 10 нчы сыйныфта укый, кечкенә кызчык быел өченчегә барган.

– Улым балаларын бик ярата. Бер дә зарланмый. Без дә кулдан килгәнчә булышырга тырышабыз. Әниләре сөенеп ятадыр, – ди Назирә апа.

«Мине онытмадыгызмы?»

«Мине онытмадыгызмы?» Социаль челтәргә менә шундый хәбәр килеп төште. Моннан биш ел элек язмышы «ВТ» битләрендә бәян ителгән Кукмара районының Төркәш авылы кызы Энҗе Гәрәевадан икән ул хат.

Ул вакытта аңа 17 яшь иде. Табиблар кызга өч айлык чагында церебраль паралич диагнозы куя. Энҗе вакытыннан алда нибары 2 кило авырлык белән туа. Район хастаханәсендә күпме дәваланып та, үзгәреш булмагач, сабыйны Казанга җибәрәләр. Ә андагы табиблар баланың авыру икәнен әйтә. «Язмышка каршы килеп булмый. Башта авыр булды. Аннары инде ияләштек», – ди әнисе Зөлфия ханым.

Энҗе – гаиләдә бердәнбер бала. Кайчандыр әти-әнисе тәрбиягә бала да алмакчы була. Әмма бирмиләр. «Авыру балагыз бар» дигән сәбәп белән кире борып кайтаралар. Энҗене аякка бастыру өчен кая гына бармый алар. «Бармаклары хәрәкәтләнсен», – дип кул эшенә өйрәтәләр. Кызчык үзе дә тиктормас булып чыга. Табибларның: «Бар да – үз кулыңда, хәрәкәтлән», – дигәнен яхшы аңлый. Өйдә шуышып йөрергә, үрмәләргә өйрәнә. Аннары әкренләп төрле күнегүләр ясый, аягында басып тора башлый. Моны күреп, әтисе белән әнисе дә кызларына ярдәмне кызганмый. Күнегүләр ясар өчен, өйләрен зурайтып, махсус зал төзиләр. Шөгыльләнү өчен кирәк-яраклар сатып алалар. Бакчага исә зур бассейн ясап куялар. Барасы килгән җиренә

йөртәләр. Татарстанның матур урыннарының барысын да күреп бетергән инде Энҗе.

– Тырышлык бушка китмәде. Энҗе өйдәге эшләрдә дә булыша башлады. Үзенең махсус велосипедында йөри. Ашарга пешерергә дә ярата. Ә иң телә п эшләгән эше – бисердан чәчәкләр үрү. Аны заказга сораучылар да бар. Үзенә ошагач, без каршы килмибез, – ди әнисе. – Бар тормышыбыз кызыбыз өчен. Шуңа күрә беркемнән дә ярдәм сорамыйбыз. Балабызның бар нәрсәсе, дәвалануы мөмкинлеге булсын өчен үзебез тырышабыз. Ел саен күпләп каз, чебешләр алып үстерәбез. Шуларны сатып көн күрәбез. Барысын да сатып алырга була. Тик сәламәтлек кенә сатылмый. Ә ул Энҗегә бик кирәк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

СӘРДӘР ТАҺИРОВСКИЙ:

«КҮҢЕЛДӘГЕ ТЕАТРГА ХЫЯНӘТ ИТӘРГӘ ЯРАМЫЙ»

Сәрдәр ТАҺИРОВСКИЙ Тинчурин театрында икенче спектаклен чыгара. Башта «Ядәч! Исемдә!» аша криминал Казан һәм үзенең балачагы, кеше язмышлары белән таныштырса, бу юлы тарихи әкият тәкъдим итә. Венгриядә популяр булган татар режиссеры Казанга нәрсә эзләп килгән, ниләр тапкан? Тинчурин театры хакында ул нинди фикердә? Без әнә шулар хакында сөйләштек.

:: Сәрдәр – бик кызыклы һәм сирәк исемнәрнең берсе. Аның мәгънәсен беләсезме?
– Ул шумер теленнән тәрҗемә иткәндә башлык, җитәкче дигәнне аңлата. Башкомандующий дигән тәрҗемәсе дә бар, тик миңа калса, бу исемгә хәрбидән бигрәк рухи мәгънә салынган.

:: Сезнең гаиләгез турында интернетта кызыклы мәгълүмат бар. Әтиегез Таһир Абдуллин үзен Идел буе болгары дип атаган, дәвалаучы, рәссам. Әниегез Гөлфирә Әхмәтҗанова – журналист, традицион булмаган медицина белән мавыккан. Аларга, мөгаен, яшәү бик җиңел булмагандыр. Ник дигәндә, тормышка, вазгыятькә карашлары үзгә, фикерләрен курыкмыйча әйтә алганнар.
– Алар – ирекле кешеләр. Җәмгыять белән каршылыклар булса да, үз фикерләреннән чигенмәгәннәр. Мин әнә шундый ирекле мохиттә тудым, үстем. Шунысы да бар: алар башка фикерләрне дә тыңлый, кабул итә иде. Ә бу – бик әһәмиятле нәрсә.

:: Сезгә алты яшь тулгач, гаиләгез Венгриягә күченгән. Мөгаен, бу ил очраклы сайлап алынмагандыр.
– Миңа калса, монданиндидер үзенчәлекләр бик исәпкә алынмагандыр. Сәбәп гади: ул чакта көн күрү җиңел булмаган. Аннан соң бит әле Чернобыль һәлакәте булды, бу фаҗига дә безне урап узмады. Кызганыч, һәлакәт вакытында ул урынга бик якын булганбыз. Минем бит әби-бабаларым бер яктан – Болгариядән, ә бер як әби-бабайлар – Казанныкылар.

:: Казан ул чактан бу көннәргәчә ничек үзгәргән? Кабул иттегезме шәһәрне?
– Беренче тапкыр декабрьдә кайттым, үземне бик әйбәт хис иттем, ошаган иде... Хәзер инде Казан гына түгел, дөнья үзгәрә... Ә ул чакта миңа бик рәхәт иде. Күптән кар күргәнем булмаганга да, балачагым эзләреннән узганга да. Мин бит Казанның Һади Такташ урамында тудым, җәйләребез Аракчино бистәсендә, Илдар Хановның гыйбадәтханәсе янында диярлек узды. Алма бакчасы, Идел буе, анда су коенулар хәтергә бик нык уелып калган. Ләкин ул чакта гыйбадәтханә төзелмәгән иде әле. Мин Илдар Хановны үзем белмим инде, әбием Хаҗәр, мөгаен, аларны белгәндер. Ул бит Казанның «Әкият» кафесында төп кешеләрнең берсе иде. Менә бу юлы кайткач та Аракчинода булдым, күршеләр белән очраштым. Алар әбине хәтерлиләр әле. Бу юлы алай күп йөрергә туры килмәде, чөнки бик аз вакыт эчендә спектакль чыгарырга кирәк иде. Мин монда бер иртәдән икенчесенә кадәр эшлим, көнгә бер мәртәбә, төнлә генә тукланам. Репетиция вакытында унар минутка ике мәртәбә генә тукталам. Актерлар үз өлешләрен тәмамлагач, ял итә, билгеле, мин исә бүленмәскә тырышам.

:: Читтән килгән кеше татар милли театрын ничек күрә? Тинчурин театрыннан кала башкаларында булдыгызмы?
– Булдым һәм Тинчурин алар арасында традицион, хәтта консерватив театр булуы белән аерылып тора икән дигән фикергә килдем. Монда элеккеге энергия. Мин театр соңгы 30–40 елда үзгәрә дип уйлый идем, ә монда шундый спектакльләр күрдем: алар кырык ел элек ничек куелган – шулай калган. Мөгаен, аларны минем әбием дә карагандыр. Мин дә, ул нәрсә күрде, ул чакта шәһәрдә нинди энергия булган икән дип кызыксынып карадым.

Бу театрга баш режиссер Туфан Имаметдинов чакырганга килдем. Без бер-беребезне ун еллап беләбез инде. Ул чакта Туфан Румыниядә спектакль куя иде, мин актерларга аның сүзләрен русчадан мадьяр теленә тәрҗемә иттем. Венгриядә дә театрлар үзгәрә, монда да соңгы елларда үзгәрешләр бар кебек. Бу – Туфанның экспериментал режиссерлар чакыруында гына чагылмый, ул, шул исәптән мин дә театрны музей дип кабул итә алмыйбыз. Театр үсәргә тиеш. Бу юлда хаталар да ясалырга мөмкин, начар постановкалар да куела ала. Чөнки режиссер ул барысын да күрүче Алла түгел, ул бары тик сизә, тоемлый гына ала. Ул белми, могҗизалар ясый алмый. Дөрес, могҗиза белән репетиция вакытында очрашып була. Әмма ул йә була, йә юк. Һәм аны булдыруның идеаль алымы да юк. Кайчак, кайчан «нормальный» спектакль чыгарасыз инде, дип тә сорыйлар. Андый консерватив карашлар монда да, Венгриядә дә, бөтен җирдә дә бар. Тинчурин театрында бигрәк тә. Бит биредә үзгәртеп коруларга кадәрге театраль алымнар да сакланган! Тарих китабы бер читтә торсын.

:: Консерватив дигәннән, монда бит тамашачы яңалыкларны бик өнәп бетерми. Мәсәлән, Тинчуринның «Умай» лабораториясе эшен кабул итмәделәр.
– Тамашачыны алдарга ярамый. Әгәр без тамашачыга ошаган продукт тәкъдим итәбез икән, бу – алдау, үзеңне сату. Дөрес, бүген тамашачы шуны тели, ә бу нормаль хәл түгел. Аңа сериаллар ошый, бу бит инде югары сәнгать тә, Шекспир да, Тинчурин да түгел. Тинчурин, мәсәлән, «Турандык»та трагедия өлешен алган. Без аңа азрак комедия дә өстәдек. Консерватив тамашачыга ярыйм дип, көтүгә иярергә ярамый чөнки. Мин бик җайлы гына «сабын куыгы операсы»н да куя ала идем. Тамашачыга ошар, тик бу театр эше булырмы соң? Театрга хыянәт итәргә ярамый. Бигрәк тә күңелдә яшәгән театрга. Тамашачы үзенә ошаганны таләп итә ала, билгеле. Миңа аны бир, моны бир, дип сорый ала. Нәкъ бәйләнчек бала кебек. Ә бәйләнчек баланың җаенда торырга кирәкме? Миңа калса, аны тәрбияләргә кирәк. Юкса аннан киләчәктә шәхес килеп чыкмаска мөмкин. Безнең максат тамашачыны әлегәчә аңа таныш булмаган күренеш, алымнар белән кызыксындыру. Театр әнә шул яңалыкларны эзләве белән кыйммәтле дә инде ул. Бу алым эшли, шул юлдан барыйк дисәк, бу – әйткәнемчә, алдау һәм актер хезмәтен сату. Алайса, аның өчен театрга йөреп торырга да кирәкми, сатылган кешеләрне күрәсегез килсә, аларның үз урыннары бар.

Актер бик нәзберек җан бит ул. Әйтик, миннән бер актриса: «Бию булачакмы, мин җырлаячакмынмы соң?» – дип сорады. Мин аңа: «Әйе, җыр, бию бик яхшы эшли, бик җәлеп итә, әмма сез тагын да зурракка лаексыз», – дидем. Кичә прогоннан соң сөйләштек, ул инде үз көченә ышанган иде. Актер яңа чикләр ачканда гына үзенең ышанычын, милләтен аклый ала. Тинчурин да бит үз вакытында прогрессив кеше булган, яңалыклар керткән. Без шундый шәхескә хыянәт итә алмыйбыз бит инде. Алга барырга, прогрессив спектакльләр куярга кирәк.

:: Сүз уңаеннан, «Турандык»ның ни өчен нәкъ менә Тинчурин тәрҗемәсен алырга булдыгыз?
– Аны миңа Кәрим Тинчуринның 135 еллыгы уңаеннан Туфан Имаметдинов тәкъдим итте. Әмма без аны театр актеры Илфак Хафизов белән редакцияләдек һәм Карло Гоццины оригинал текстыннан да байтак өлешләрне керттек. Нәтиҗәдә нигездә Тинчурин күзаллавы ята, ул фәкать баетылды гына. Мин спектакль вакыйгаларын әнә шундый чишелештә күрдем.

:: Тагын бер момент бар бит әле. «Хан кызы Турандык» спектакле Камал театрында да куелды. Тамашачы телиме, теләмиме, ике куелышны чагыштырачак. Кайсындыр уңышлы, кайсындыр уңышсыз, бәлки, кабатлау, дип бәя бирәчәк. Сез шундый чагыштыруларга, бәяләүгә әзерме?
– Һәрвакыт чагыштырачаклар инде. Әйтик, Румыниядә куйсам да, минем икенче спектакльне беренчесе белән чагыштырачаклар. Кешенең табигате шундый, нишлисең. Камал театрында ничек куелгандыр, белмим, миңа калса, бу бөтенләй башка спектакль булачак. Чагыштырырга кирәкмидер. Әйтик, Тинчурин Карло Гоццины үзенчә аңлаган һәм үзенчә эшкәрткән. Без тамырларны истә тотып, көнбатыш белән көнчыгыш Европаны һәм Шәрык дөньясын берләштерергә тырыштык. Анда, бу хәл Кытайда булганмы, дигән сорау да бар. Гоцци бит Кытай хәлләре турында язмый, ул Көнбатышның яки Европаның Кытай турында ни уйлавын яза. Бу – Кытай турында әкият. Аны аңларга һәм кабул итәргә кирәк. Шуңа да ул «Мең дә бер көн» дип атала. Монысын исә Шәһрезадәнең «Мең дә бер кичә»се белән бутарга ярамый. Бу – бик борынгы әкият.

:: «Турандык» – сезнең икенче эшегез. Аңа кадәр үзегез турында спектакль куйган идегез.
– Бусы да азрак үзем турында инде. Нинди генә әсәргә алынма, барыбер үзең килеп кушыласың. «Ядәч»кә килсәк, ул да бит минем балачак турында гына түгел, ул коллектив тәҗрибә булды. Без сәясәткә түгел, кешеләр язмышына кагылдык. «Турандык»та исә Көнбатыш белән Көнчыгыш илләре очрашуы. Миңа калса, хәзер дөньяда бу очрашуларның кульминациясе. Дөнья кечерәеп калды кебек, беркая качып котылып булмый. Үз фикерең белән ялгызың калып булмый. Фикерләр бөтен тарафтан сиңа агыла да агыла... Турандыкның система белән проблемалары бар. Дөнья бит ул, глобаль алганда, акылдан шашкан. Шуңа күрә Турандыкны да акылдан шашкан дип саныйлар. Ул бит дөнья аркасында акылыннан шаша. Һәм бу безнең барыбызга да кагыла. Башкалар да шулай тояр дип уйлыйм.

> Без театрга барыбыз да ялгыз килеп керәбез. Шул вакыт берсе көлеп куя, аның кәефе сиңа килеп бәрелә һәм син дә көләсең. Кемдер еласа, син дә аның хисләрен аңлыйсың. Әгәр инде телефоныңа багынмаган булсаң. Театр ул – шундый җир: монда ялгызлык та гомумигә әйләнә, шатлык та уртакка. Монда шуннан да олырак могҗиза була алмый. Берзаман син башка кешене аңлый башлыйсың һәм сез бергәләп нәрсәдер эзли башлыйсыз. Син, бер караганда, тик утырасың, ә эчтә активлык бара. Син күңелеңнән актерга ярдәм итә башлыйсың. Безнең культура (зәвык) интернет комментлары хәлендә түгел әле дип өметләнәсем килә. Әмма... Без гаепли һәм нәтиҗәләр генә эзли торганга әйләндек шул.

Шуңа күрә репетициягә чит кешеләрне кертәсем килми. Чит кеше актерның бүген бик үк яхшы халәттә булмаган чагына туры килергә мөмкин. Ул бит атналар буена сузылган процессны күрми һәм нәрсә инде бу (!) дип гаепли башлый. Әлбәттә инде, бер-береңне йолыккалый башласаң, могҗиза тумый. Могҗиза эзләү юлында безгә барыбызга да кемнәргәдер каршы торырга, кыю булырга, хәтта хаталанырга да туры килә. Ә кыюлык кирәк. Кыюлык җитмәсә, актерларга хыянәт итәчәкбез. Алар үзгәрергә, тәҗрибәләр аша узарга тиеш. Андый юл узмасалар, алар бары тик хезмәтчеләр хәлендә калачак. Алар хезмәтче түгел.

> Актер кеше колы түгел, ул – Алла колы. Үзебезне Алладан өстен куярга ярыймы соң? Тамашачы телефонын кабыза икән, ул үзен актердан өстен куя. Телефон кабына икән, залдан чыгып китү хәерле.

Моннан берничә ай элек вафат булган бөек режиссер Питер Брукның (ул да инглиз патшабикәсе кебек үк карт иде инде) Римда спектаклен карадым. Спектакль вакытында кемнеңдер кулында экран кабынып китсә, янына барып, сүндерегез, дип кисәтәләр иде. Шушы кагыйдәне үзләштерергә кирәк. Театрда үзеңне телевизор каршындагы кебек тотарга ярамый. Монда безнең алда тере кешеләр. Алар алдында ваемсыз кыланып, күңелләрен үтерәбез бит. Ошамый икән, чыгып китәргә кирәк. Гадел булыйк, ниһаять!

:: Хәзерге вазгыятькә туры килгән тагын нинди пьеса куяр идегез?

– «Турандык» заманга бик туры килә. Анда бар да бар. Карагыз, нинди матур декорация (буш сәхнәгә төртеп күрсәтә). Әйе, бу – ирония. Әгәр язылганча бай декорация корып булмый икән, талпынырга да кирәкми. Арзанлы нәрсә ул бөтен мәгънәне боза. Шуңа без байлыкны костюмнарда чагылдырдык, ә декорация урынына бушлык һәм сәхнәдән залның буеннан буена сузылган лампочкалар гирляндасын гына кулландык.

:: Казанда яшәп иҗат итә алыр идегезме?

– Әйе.

:: Монда салкын, дөнья соры булып тоелмыймы?

– Йөрәгеңдә җылылык булса, салкын куркытмый.

:: Татарча сүзләр запасы арттымы соң?

– Акрынлап арта. Сүз саен Аллабирса дип кабатлый башладым. Вакыт аз бит, ә актерлар мин аңласын өчен һәр җөмләне тәрҗемә итеп баралар. Ә кайчак мин яңгыраш һәм татар музыкасы ярдәмендә аңларга тырышам. Килеп чыга кебек. Аң уяна.

:: Әтиегезне Казанга алып кайтыр идегезме?

– Аны ничек кабул итүләрен белеп булмый бит. Аны аңларлармы? Берничә ел элек Казанга кайтып килде ул, монда аның эзләре бар. Мәсәлән, Горький паркында Сәрдәр Вәисов каберендә аның һәйкәле тора. Ул аны Советлар Союзы вакытында, Киевтан ерак булмаган бер шәһәрдә ясады. Аны ике шешә аракы хисабына Казанга кайтарып җиткерделәр. Ул рәссам да, экстрасенс та. Венгриядә эти бик популяр, китаплары да бар. Аны бик күп җирләргә чакыралар, әмма ул үзенең күңелен сатмый. Әни исә журналист иде. Мин бит балачакта Чернобыль һәлакәте аркасында авырдым. Бу хакта бик сөйлисем дә килми инде… Эти белән әни Казаннан минем хакка күченделәр. Аннан соң туксанынчы елларда Һади Такташ урамында үсмерләр наркотиклар белән бик мавыгалар иде. Без дүү әни яки әни белән подъездга кергәндә, еш кына кулында урын калмаганлыктан, аягына шприц кадап маташкан кешеләргә тап була идек. Шуңа киттеләр алар.

:: Бу юлы Казан урамнарында йөрергә вакытыгыз булмагандыр инде.

– Бик аз булды. Әмма «Әкият»кә барып килдем. Бәлки, әбием Хаҗәр традицияләре саклангандыр, дип бардым. Һәм өчпочмак алдым. Ошады.

:: Ихлас әңгәмә өчен рәхмәт!

– Беләсезме, мин үземне тамашачыдан өстен куярга теләмим. Үземне аңа лаек дип санамыйм. Монда кешеләр күңел җылысын эзләп килә дип уйлыйм. Шундый спектакльләр караганым бар: анда тамашачы белән спектакль арасында энергия туа. Бу спектакль – тәҗрибә, әмма тамашачыга ул якын булыр дип уйлыйм.

Әңгәмәдәш –
Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ИНША

МИДХӘТ САДЫЙКОВ
(ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ)

Бөтен кешенең коронавирустан сакланып, өйдә бикләнеп яшәгән чагы. Апрель аенең өченче атнасы үтеп бара инде. Тик әлегә урамга чыгарга ярамый, штраф салалар. Чалт аяз көн, эссе. Чөнки быел карлар март аенда ук эреп бетте. Мин балконга майкадан гына чыгып, әзрәк кызынып алырга ният иттем. Кояш үзе дә бүген волонтер булган, тәрәзәдән тәрәзәгә күз салып, балконнан балконга күчеп, Д витамины таратып йөри. Балконда кызынучылар бер мин генә түгел, ахры. Аннары… балконнар бит хәзер аквариум кебек, үтә күренмәле. Әнә каршы йортта яшәүче Әхмәй (иртәнге якта аларга кояш төшми), бинокльдән, бик тырышып, кемнедер күзәтә. Минем күршедә яшәүче Зинаны түгел микән. Ник дисәң, ул шулай балконга раскладушка куеп, шунда чыгып ятарга ярата. Нудистка. Латвиягә сеңлесе янына кунакка барган саен, нудистлар пляжында су кереп йөргәннәрен бер исе китмичә үзе сөйләгәне бар.

Менә Әхмәй янына хатыны чыкты, иренең кулындагы биноклыне алып, ул да бу якка күз салды, аннары тиз генә балкон ишеген ябып, икесе дә өйләренә кереп киттеләр. Сугышалармы, юкмы, анысын алар гына белә…

Мин бераз әйләнә-тирәне күзәтеп утыргач, шәһәр читендә үз йортлары белән яшәүче сабакташ дустым Айвазга шалтыратам, хәлләрен сорашам.

– Шөкер. Ихата тирәсендә кайнашабыз. Аннарымы? Хатын белән чиратлашып инша язабыз, – ди.

– Нинди инша?

– Нинди дип, инша инде. Оныгыбыз быел 9 нчы сыйныфны тәмамлый. Бер татар теленнән генә «4ле» чыгарасы килми бит. Онлайн укытуга күчкәч, тел-әдәбият укытучысының дәресләрен декрет ялында утыручы кызы алып бара башлады, чөнки анасы компьютерда эшли белми. Ә ул, өй эше итеп, балаларга һаман инша язарга куша. Әнисе, бозаулары булуына карамастан, тагын кырыклап бройлер чебеш тә алып җибәрде, күбрәк шулар тирәсендә кайнаша. Йортларыбыз чапырыш кына булгач, барысын күреп торабыз. Әләкләшеп йөреп булмый бит. Бала хакына ярар инде дибез, түзәбез.

– Әйбәт шөгыль бит инде. Хәтерне яңартып тору өчен, кемдер шахмат уйный, берәүләр кроссворд чишә.

– Шулаен шулай да…

– Темалары программа буенчамы соң?

– Төрлесе бар, ирекле темага да. Соңгысы – мәхәббәт темасына. Имеш, өлкән буын кешеләре арасында аерылышучылар булмаган. Мәхәббәтнең, гаиләләрнең тотрыклылыгы нидә булуын ачыклап, ата-аналар белән бергәләп язарга кушылган. Кайда ничек танышканнар, фәлән-төгән шунда.

– Шпаргалка тарихыннан башлап китсәгез була бит инде, – дидем мин. Без көлештек.

– Булуын була да… Ни әбисе язарга алынмый, ни минем кул бармый.

– Укытучылары мин белгән кеше түгелме икән, телефонын җибәр әле, – дим.

…Шпаргалка тарихы дигәннән, без өчебез дә география факультетында белем алдык. Мин Айваз белән тулай торакта да бер бүлмәдә яшәдем. Ул армия сафларыннан соң укырга керде, кечкенә якларда эшләп укыды, шунлыктан еш кына лекцияләрне дә калдыргалый торган иде.

Гөлназ – Казан кызы. Тулай торакта яшәмәгәч, аның белән беренче курста бик аралашмадык. Лекция башланыр алдыннан гына килә, укулар бетүгә, кайтып китә дигәндәй. Шулай да Айваз аның белән дуслашып китү вакыйгасын кызык итеп сөйли иде. Барысы да шул имтихан, зачет бирү вакыйгаларына бәйле инде.

– Карыйм, – ди, – Гөлназ иреннәрен кыймылдата-кыймылдата сөйләргә әзерләнеп утыра. Мин болай гына, буламы дигәндәй, аңа күз кысып куям да янына килеп утырам. Аннары, бик ис китмәгән кыяфәт чыгарып, билет сорауларына күз төшерәм. Икенче сорауның азагына җиткәндә, кашларым җыерыла башлый: «Бермуд өчпочмагы»на тулы характеристика бирергә, карта янына чыгып сөйләргә». «Бетте баш, баттым», – дип уйлап куям. Шунда күңелгә бер фикер килә һәм мин янә кыюланып, Гөлназга «6» санын күрсәтәм. Ул да югалып калмый, малай, озын итәген ян-якка сыдырып төшерә дә, шпагатка утыргандагы кебек, сул аягын минем якка борып куя. Аннары: «Үзең ал», – дип, ияге белән ишарә ясый. Үзе, имеш, җавап бирергә әзерләнә. Мин тиз генә кереш (резина) белән бот төбенә кыстырып куелган егерме биш дәфтәр бите арасыннан теге санны эзләргә керешәм, тик ул 6 нчы түгел, 9 нчы билет сорауларына язылган җаваплар булып чыга. Имтиханнан соң: «Их, Гөлназ, үзең алып биргән булсаң, бәлки, стипендия дә эләккән булыр иде», – дим. Ә ул: «Ә син нигә каушадың соң?» – дип көлә дә көлә.

Менә шундый хәлләр… Утыз җиде ел бер мәктәптә эшләп, бергә ялга чыккан пар алар.

Мин кояшка аркам белән борылып утырам да Айваз биргән телефон номерын җыям.

– Исәнмесез, Гөлфинур ханым. Бу Мәгариф министрлыгыннан инспектор Гарифуллин була (үзем министрлыкның ишеге кайсы якка ачылганын да белмим инде югыйсә).

– Әйе, тыңлыйм.

– Ничек хәлләрегез? Авырмыйсызмы? Шулаймы? Мин дәресегезгә кергән идем бүген (компьютер белән эшләгән кешенең дәресен читтән күзәтеп тору мөмкинлеге бар микән, мин белмим), без бит онлайн укытсак та тикшереп торабыз, сезнең урында бөтенләй яшь укытучы утыруын күргәч, шалтыратырга булдым. Сез өйдә түгелмә әллә, әтәч кычкырган тавышлар да ишетелә…

Әңгәмәдәшем югалып калды булса кирәк, берара борын мышкылдаган тавышлар гына ишетелеп торды.

– Мин… ни… быел пенсиягә чыгам, китәрмен, ахры, – ди.

– Юк сүз сөйләп тормагыз. Сезнең кебек укытучыларны дистә еллар буе әзерлисе дә бар бит. Аннары 2021 елның Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителүен дә онытмыйк. Унҗиденче елгы «инкыйлаб»тан соң (2017) татар теле хәзер янә күтәрелештә. Министрлар да рәсми чараларда татарча сөйләшергә тырыша, прокуратура хезмәткәрләре дә балаларын татарча ихтыярый укытырга риза булып гаризалар яза… Сезгә киңәшем шул: кызыгыз янына кереп утырыгыз да дәресегезне программа буенча алып барырга тырышыгыз. Аннары тагын бер әйбер бар иде. Уку елы бетеп бара, билгеләргә игътибарлы булыгыз әле, отличникларны төшереп калдыра күрмәгез. Сау булыгыз.

Бераз уйланып утыргач, нигә шалтыраттым инде мин бу укытучыга, дип үземне сүгеп алам.

Кояш түбәгә күтәрелеп бара икән, муен да кызыша башлады. Мин янә Әхмәйләр ягына күз салам. Балконда кеше юк. Шулай да йокы бүлмәсендәге яран гөлләр арасыннан бер «былбыл»ның бу якка карап торуы шәйләнә. Зинаны күзәтә бу, точно!

Мин анда-монда суккалап, балконда «эш кырган» тавышлар чыгарып алам. Аннары, гипсокартон белән томаланган юка стенага шакып, күршемә эндәшәм:

– Күрше, ни хәлләрең бар?

– Әйбәт кенә, Достоевскийны укып ятам менә. Сез дә өйдәмени бүген?

– Әйе. Коронавирус бит, чыгарга ярамый. Ни димәкче идем… Теге вакытта краннарыңны көйләп бирә алмадым, вакыт тыгыз булды… Әллә дим, берәр эшеңне эшли торыйммы?

– Алай дисәң, совет заманында алынган стенканы сүтеп чыгарып ташлыйсы бар инде барын…

– Бәй, сүтә торыйммы соң, эшем дә юк.

– Ярамас әлегә, күзәтүчеләр дә табылмый калмас. Бөтен җир үтә күренеп тора бит хәзер. Заманалар тынычлангач, исегезгә төшерермен, күрше.

– Ярар, эшләрбез…

Гөрләвекләр йөгергән, хисләр күңел дәрьясыннан ташып чыккан, сыерчыклар оя сайлап очкан мизгелдә менә шулай балконда арка кыздырып утыр инде… Каян гына килеп чыкты соң бу үләт чире…

Карандашны тәкерекләп, инша гына язасы кала икән шул, я шигырь иҗат итәсе. Хәер, ул да – зур эш бит, башкарып чыга алсаң…

ТЕЛЕВИЗОРНЫ КӨЙЛИБЕЗ

Хак лайфхак!

Телевизорда нибары ике канал булган заманнар артта калды. Кайсы гына телевидениене алма, цифрлымы ул, кабельлеме, әллә түләнкәме, хәзер ул йөзләрчә канал тәкъдим итә. Ә бит гаиләдә һәр кешенең үз яраткан тапшырулары бар. Бу очракта телевизор пультында каналлар нумерациясен ничек көйләргә? Киңәшебез файдалы булыр.

Гаиләгезнең барлык әгъзалары да яратып караган ТВ-каналларны (әйтик, «1 канал», «Россия», «ТНВ», «Пятница» һ.б.) беренче төймәдән алып тугызынчыга кадәр көйләп куегыз. Һәр ТВ-пультта бу төймәләр бар.

Һәркемнең аерым яраткан каналлары бар. Бу очракта аларны Һәркемнең аерым яраткан каналларын болай эшләргә була. Әйтик, әти кеше «Матч ТВ», «Боец», «Рыболов и охотник» һәм «РБК» каналларын үз итә ди. Бу очракта әлеге каналларны 11, 12, 13, 14 номерларына урнаштырырга кирәк. Әти ике тапкыр «1» төймәсенә баса да, 11 нче каналга әләгә һәм алга таба «Page Up» (өскә таба) төймәсенә баскалап, үзенең яраткан каналларын буйлап гизә.

Балалар исә 33тә «ШАЯН ТВ», 34тә – «Карусель», 35тә – «Детский мир», 36да «Disney» карасын.

Телевизор карауларыгыз уңайлы булсын! Пультның кадерен белик. Элек ул юк иде. Ә пульт ролен гаиләдәге иң кечкенә кеше башкара иде.

Әз-мәз мәзәк

* * *

– Шуның белән беренче уку көнебез тәмам, балалар. Миңа сорауларыгыз калдымы?

– Гөлназ Ринатовна, ә каникул кайчан?

* * *

Минем Руслан исемле дустым бар. Таксист ул. Такса токымлы өч эт тота.

* * *

Ә бит кеше койрыклы булып туса, ничек шәп булыр иде! Койрыгың белән чебен куасың, ә кулыңда – смартфон!

* * *

– Синең иң яхшы сыйфатың нинди?

– Мин ялкау.

– Ялкау кешеләр таза була бит, ә син ябык.

– Ашарга иренәм.

* * *

Сезгә теләгем шул: быел көзге курткаларыгызда барыгыз да йөзәр сум акча тапсын!

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Насыйри, Аргамак, Лачын, ары, текст, Албастылар, Ум, Дәминов, ят, Кальве, әз, ураза, Карамалы, ура, ТТ, ия, Ульян, Кара, Ока, Умырзая, Зинира, куак, Кораб, рэпер, сәрдә, арматура, триммер.

Вертикаль: Нардуган, уку, Зөлфия, яр, батальон, яки, кайнар, туа, Илшат, ымлау, Карасу, реал, Рэмбо, әр, ачлык, рапира, Сәрдек, ир, Ансат, ат, зөбәрҗәт, умыртка, аяк, номер, По, ага, Вәли, Кабаева, зыялы, Мансур.

Идел буенда ... еллары
Элек Чаллыда чыккан журнал
Бире түгел
Л.Ихсанова «... кыз»
Сүзләр «мәрҗәне»
Арча гласы
Балтач районы авылы
Татарстан вертолеты
Г.Гыйльманов китабы
Оргаизмдагы багана
Язучы Элдгар ...
Ул да үз эшендә, Гали дә
Аны моряк кузли
Бернича рота
Бала үз ризыгы белән ...
Томск өлкәсендә елга
Бразилия акчасы
Опера җырчысы Руслан ...
Төрки халыклар бәйрәме
Чит
Майонез маркасы
Кунакханә бүлмәсе
Күп түгел
Сәхәр һәм ифтар арасы
Сүзсез ишараләү
Аны Сталлоне уйнады
Энә белән кое казу
Теркәгеч
Яу кычкыруы
«... Гобәй, туып үскән авылым»
«Ауди» төре
... һәм хәбәр
Сембер
Халык көе, Ә.Фәйзи сүзләре
Хатын түгел
Кешни торган хайван
Язучы Карим ...
Ризат һәм ...
Кечкенә машина
«... хит» хит-парады
«... чишмә чылтыр-чылтыр»
Интеллигент
Аксубай районы авылы
Фехтование коралы
55 еллык туй
Табаннан ботка кадәр
Агачның энекәше
Ильяс Гафаров, Тимати
Дәрдмәнд шигыре
Тиргәү
Купеллык үлән
Бетон эчендә чыбык
Үләнне һәм чәчне кисә

Беләсең килсә...

1 **Әмирхан Еники Казанга килгәч, иң элек кем булып эшкә урнаша?**
а) итекче;
б) кибетче;
в) курьер.

2 **Бу шәһәрдә 2000 елда җәйге Олимпиада узды.**
а) Сидней;
б) Барселона;
в) Пекин.

3 **Менделеев таблицасында ничә химик элемент бар?**
а) 116;
б) 118;
в) 112.

4 **Иң кайнар планета нинди?**
а) Сатурн;
б) Марс;
в) Венера.

Җаваплар: 1.в); 2.а); 3.б); 4.в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 335

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+